Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова

# ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ 9

## Методик әсбап



Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова

# ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ

**9 нчы сыйныф**

Методик әсбап

Төп гомуми белем бирү оешмаларында
(туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

КАЗАН
2024

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)
А12

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтында эшләнде

**Абдуллина Д. М.**

А12 Родная (татарская) литература. Туган телдәге әдәбият. 9 класс. Методическое пособие : для преподавателей образовательных организаций основного общего образования, работающих с обучающимися, владеющими родным (татарским) языком / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мухарлямова. — Казань, 2024. — 109 б.

Методик әсбапта 9 нчы сыйныфта «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметыннан дәреслек белән эшләү тәртибе яктыртыла. Биредә предметны өйрәнүгә куелган максат-бурычлар, планлаштырылган нәтиҗәләр, тематик планлаштыру, дәрес эшкәртмәләренең үрнәкләре бирелә.

Әсбап урта сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)

© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2024
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2024
© Абдуллина Д. М., Мөхәрләмова Г. Н., 2024

## ХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ!

Әлеге методик ярдәмлек укытучы хезмәтен, дәреслек белән эшләүне беркадәр җиңеләйтү, юнәлеш бирү максатында әзерләнде.

Әдәбиятны укыту методикасы хәзерге таләпләрне истә тотып, узгандагы уңышлы мөмкинлекләрдән заманча файдаланып, киләчәккә йөз тотып эшләүне сорый.

Хәзерге көндә бу уку предметы әдәбиятны фән буларак кына тәкъдим итеп калмый, сүз сәнгатен милли хәзинә, халкыбызның тарихы, традицияләре, милли фәлсәфәсе, холкы, инанулары, бөек шәхесләре белән бәйләп укучыга җиткерүне максат итеп куя. Башкача әйткәндә, үз халкына тирән хөрмәт саклаган, аның дәвамчысы була алырлык милли рухлы шәхес тәрбияләү бурычын да үз өстенә ала.

Әдәбият дәресләрендә халыкның матди һәм рухи кыйммәтләре белән танышу аша буыннан буынга тапшырыла торган тарихи, мәдәни, әхлакый һәм эстетик тәҗрибәне актив үзләштерү алып барыла. Туган әдәбиятны өйрәнү укучыларда аны милли мәдәниятнең бер өлеше буларак кабул ителәторган мәдәни хәбәрдарлык компетенциясен формалаштыра. Әдәбият аша кеше үзенең мәдәни тәңгәллеген үзләштерә, үз халкы әдәбиятының гомуми әдәби процесс һәм дөнья мәдәнияте сәнгате белән аерылмас бердәмлеген аңлый. Шул ук вакытта үзенең этномәдәни үзенчәлеген генә түгел, ә дөнья мәдәниятеннән аерылгысызлыгын, аның бер өлеше булуын да таный. Шулай итеп, туган телдәге әдәбият укучылар үсешендә аерым урын алып тора, алар өчен мөһим кыйммәтләр, рухи-әхлакый карашларны җиткерү вазифасын үти, милли һәм дөнья мәдәнияте кыйммәтләрен, татар халкының рухи байлыгын һәм тормыш фәлсәфәсен танып белүгә һәм үзләштерүгә, милли үзаңны, шулай ук Гомумроссия гражданлык аңын формалаштыруга турыдан-туры ярдәм итә.

Әдәбият — заман куйган таләпләр югарылыгында шәхес тәрбияләү һәм интеллектуаль, әхлакый-эстетик үсешнең

дәрәҗәсен билгели торган төп предметларның берсе. Матур әдәбият әхлакый идеаллар турында күзаллауны, кешенең үзенә, дөньяга иҗтимагый һәм эмоциональ-кыйммәти мөнәсәбәтен формалаштыруны тәэмин итә һәм туган телне үзләштерү, камилләштерүдә дә төп җирлек булып тора.

Әдәбият дәресләрендә мөстәкыйль үсеше өчен әдәбиятны өйрәнүнең әһәмиятен аңлый, үз фикерен телдән һәм язмача дөрес тәкъдим итә һәм дәлилләп җиткерә белә торган укучы тәрбияләнә. Алай гына да түгел, укучы дөньяны һәм бу дөньяда үзен танып белү өчен, даими китап уку ихтыяҗы кирәклеген аңлый.

Мәктәптә әдәбият укытуның максаты шулай ук әдәби әсәрләрне эмоциональ кабул итү, образлы һәм аналитик фикерләүне үстерү, иҗади күзаллау, әсәр текстларын эчтәлек һәм форма берлегендә үзләштерү, төп тарихи-әдәби мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне өйрәнү, әдәби әсәрләрне уку һәм анализлау күнекмәләрен булдырудан гыйбарәт. Моннан тыш әсәрләр укучыларның телен баету, аларның сөйләм культурасын һәм коммуникатив күнекмәләрен формалаштыруда төп чыганак та булып тора.

9 нчы сыйныфта туган телдәге әдәбият предметын укытуның төп максаты — татар әдәбиятының барышын, аерым чорлардагы торышын, чор әдәбиятының йөзен билгеләүче язучылар иҗатын анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.

Бу уку елында укучылар борынгы язма истәлекләрдән башлап, хәзерге көнгә кадәр булган әдәби мирасыбыз белән танышалар. Әдәби барыш үзенчәлекләрен, әдәбиятны чорларга бүлүнең нигезен үзләштерәләр. Һәр әдәби чорның төп билгеләре, күренекле әдипләренең эшчәнлеге, язучыларының тормыш юлы, иҗатының таҗы булган әсәрләр белән танышалар. Язучы иҗатының чор белән, янәшә яшәгән халыклар әдәбияты, гомум әдәби барыш белән бәйләнешләрын күзалларга тиеш булалар.

Хакимлек иткән идеологиянең сүз сәнгатенә, иҗат әһелләренә йогынтысы карала.

9 нчы сыйныф укучысы әдәби барышны тулы бер процесс буларак күз алдына китерә, заман героена бәя бирә, үзенчәлекләрен күрсәтә ала.

Туган телдәге әдәбиятны масштаблы күзаллау укучыга халыкыбыз тарихын, аның үсеш юлларын ачыкларга да ярдәм итә.

## «ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ» УКУ ПРЕДМЕТЫННАН ФЕДЕРАЛЬ ЭШ ПРОГРАММАСЫ

1. «Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметыннан федераль эш программасы (предмет өлкәсе — «Туган тел һәм туган телдәге әдәбият») (алга таба — туган (татар) телдәге әдәбияттан программа, туган (татар) телдәге әдәбият, татар әдәбияты) туган (татар) телендә һәм рус телендә белем бирүче оешмалар өчен туган (татар) телдә сөйләшүче укучылар өчен эшләнде, һәм аңлатма язуын, уку-укыту эчтәлеген, туган (татар) телдәге әдәбияттан программа үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләрен үз эченә ала.

2. Аңлатма язуы туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең төп максатларын, уку планы структурасындагы урынын, шулай ук эчтәлекне сайлап алуга, планлаштырылган нәтиҗәләрне билгеләүгә юнәлешләрне чагылдыра.

3. Уку-укыту эчтәлеге төп гомуми белем дәрәҗәсендә һәр сыйныфта мәҗбүри өйрәнү өчен тәкъдим ителгән эчтәлек юнәлешләрен ача.

4. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре төп гомуми белем бирү дәрәҗәсендә барлык уку чоры өчен шәхескә бәйле, метапредмет нәтиҗәләрне, шулай ук һәр уку елы өчен предмет нәтиҗәләрне үз эченә ала.

5. Аңлатма язуы.

5.1. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программа укытучыга белем бирүдә заманча тенденцияләргә һәм актив укыту методикаларына юнәлдерелгән эш программасын булдыруда методик ярдәм күрсәтү максатыннан эшләнде.

5.2. «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметы шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсеш дәрәҗәсен билгеләп торган гуманитар белем бирү юнәлешендәге төп предметларның берсе булып тора. Туган телдәге әдәбиятны өйрәнү тормышны танып белергә һәм чынбарлыкны модельләште-

рергә ярдәм итә, сүз-сурәт чаралары ярдәмендә дөньяның художестволы картинасын булдыра һәм аңа билгеле бер мөнәсәбәт тудыра, югары дәрәҗәдәге эмоциональ тәэсиргә ия.

Әдәби белем укуның һәм әдәбиятны өйрәнүнең үзенең шәхси үсеше өчен әһәмиятен аңлаган, үз фикерен дәлилли һәм аны телдән һәм язма формада тәгъбир итә алган, шулай ук кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен гармонияләштерү, дөньяны тану һәм үзен бу яшәештә күрә белү чарасы буларак системалы рәвештә укуга ихтыяҗы формалашкан укучы тәрбияләү белән бәйле.

5.3. 5—9 нчы сыйныфларда туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү укучыларның татар әдәбияты әсәрләрен үзләштерүен, художестволы форма һәм эчтәлек бердәмлеге принципларына таянып шәрехләү һәм анализ күнекмәләрен үстерүне; милли үзаңны үстерү, этник чыгышны аңлау, системалы белемнәр алу өчен шартлар тудыру үз халкының тарихы, теле, мәдәнияте, дөньяга карашы, менталитеты, фәлсәфәсе турындагы белемнәрне тәэмин итә.

5.4. Уку предметы гуманитар циклга караган башка уку предметлары белән, аеруча «Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәбият» уку предметлары белән предметара бәйләнешләрне тәэмин итә.

5.5. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программаның эчтәлегендә түбәндәге юнәлешләр аерып чыгарыла:

халык авыз иҗаты (әкиятләр (тылсымлы, көнкүреш, хайваннар турында әкиятләр), мифлар, риваятьләр, легендалар, халык авыз иҗатының кече жанрлары (табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр), татар халык җырлары, дастаннар, бәетлар; татар фольклоры 5—8 нче сыйныфларда тәкъдим ителә);

чорлар буенча татар әдәбияты (әдәби әсәрне мөстәкыйль сәнгать әсәре һәм катлаулы әдәби процессның бер чылбыры буларак карау; татар әдәбиятын аның үсеш этапларына туры китереп өйрәнү, Урта гасырлар, XVIII гасыр, XIX—XX гасырлар әдәбиятларыннан башлап хәзерге татар әдәбиятына кадәр; туган телдәге әдәбиятта тарихи вакыйгаларның чагылышын күзәтү, тарихи барышта татар әдәбиятының роле турында күзаллауларны киңәйтү);

әдәбият теориясе (конкрет әдәби әсәрләрне өйрәнү процессында теоретик-әдәби төшенчәләрне үзләштерү: вакыт һәм сәнгать формалары арасындагы өзелмәс бәйләнешне күзәтү процессында әдәбият төрләре һәм жанрлары проблемасын карау, 5 нче сыйныфта аерым әсәрләр мисалында проза, лирика һәм драма үзенчәлекләре өйрәнелә, 6 нчы сыйныфта лирик әсәрләрдә, хикәядә һәм повестьта, лиро-эпик әсәрләрдә, драма әсәрләрендә, шулай ук фантастик, автобиографик характердагы әсәрләрдә образлылык тудыру алымнары карала, 7 нче сыйныфта укучылар хикәя, повесть, роман, драма, лирик һәм лиро-эпик әсәрләрнең жанр хасиятләрен беләләр), 8 нче сыйныфта өйрәнү объекты булып әдәби алымнар (пейзаж, портрет, символ, нәфис деталь һәм башкалар) тора, 9 нчы сыйныфта татар әдәбияты тарихы өйрәнелә.

5.6. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү түбәндәге максатларга ирешүгә юнәлдерелгән:

туган мәдәниятнең мөһим өлеше буларак туган (татар) телдәге әдәбиятка кыйммәти мөнәсәбәт тәрбияләү;

укучыларны үз халкының мәдәни мирасына һәм гореф-гадәтләренә якынайту;

үзбелем чарасы буларак үз уку эшчәнлеген куллана алган грамоталы укучы формалаштыру.

5.7. Программаны гамәлгә ашыруның куелган максатларына ирешү туган (татар) телдәге әдәбият буенча түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүне күздә тота:

әдәби текстка комментарийлар бирү, анализлау һәм шәрехләү күнекмәләрен үстерү;

укучыларны әдәбият белемендәге анализлау элементларын кертү, аерым теоретик-әдәби төшенчәләр белән таныштыру аша сүз сәнгате буларак туган (татар) телдәге әдәбиятка якынайту;

татар әдәбиятының барышы белән танышу һәм аның тарихи барыш белән бәйләнешенә төшенү;

укучыларның коммуникатив күнекмәләрен (татар телендә сөйләм һәм язма диалогик һәм монологик сөйләмнәрен) үстерү;

уку күзаллауларын формалаштыру;

укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру;

укучыларның туган (татар) телдә иҗади эшчәнлеккә сәләтләрен үстерү;

гомум уку күнекмәләрен һәм универсаль уку гамәлләрен үзләштерү.

5.8. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сәгатьләрнең гомуми саны — 170 сәгать: 5 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 6 нчы сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 7 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 8 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 9 нчы сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать).

10. 9 нчы сыйныфта уку-укыту эчтәлеге.

10.1. Сүз сәнгате буларак әдәбият. Сүз сәнгатендә тормышны сәнгатьчә чагылдыруның үзенчәлеге. Татар әдәбиятын чорларга бүлү.

10.2. Татар әдәбияты тарихы.

10.2.1. Урта гасыр төрки-татар әдәбияты. XII гасыр — XIII гасырның беренче яртысында әдәбият. Чор үзенчәлекләре.

Кол Гали, «Кыйссаи Йосыф. Йосыф һәм Зөләйха образлары. Мәхәббәт көче. Поэмада гуманизм һәм гаделлек идеяләре. Поэманың сәнгати үзенчәлеге. Коръән сюжетларының татар әдәбияты белән бәйләнеше.

10.2.2. XIII гасыр — XV йөзнең беренче яртысында әдәбият. Әлеге чор әдәбиятына гомуми характеристика.

С.Сарай, «Сөһәйл вә Гөлдерсен». Поэманың идея-эстетик эчтәлеге, сәнгати үзенчәлеге. Мәхәббәтне шәфкатьсезлек һәм гаделсезлеккә каршы кую.

10.2.3. Казан ханлыгы чоры татар әдәбияты. Әлеге чор татар әдәбияты үсешенең үзенчәлекләре.

Кол Шәриф, «Гафил торма». Әдәбиятның дидактик, үгет-нәсыйхәткә нигезләнгән эчтәлеге. Дини һәм дөньяви эчтәлекнең бердәмлеге. Кеше тормышында белемнең роле.

10.2.4. XVII гасыр татар әдәбияты. XVII гасыр татар әдәбияты үсешенең үзенчәлекләре. Суфичылык әдәбияты. Әдәбиятның әхлакый-фәлсәфи юнәлеше.

М. Колый, Хикмәтләр. Хикмәтләрнең проблематикасы. Лирик геройның әхлакый карашлары, рухи кичерешләре.

10.2.5. XVIII гасыр татар әдәбияты. XVIII гасыр татар әдәбияты үсешенең үзенчәлекләре. Әдәбиятның халык тормышы белән якынаюы.

Г. Утыз Имәни, «Гыйлемнең өстенлеге турында», «Егет булу турында», «Татулык турында». Әсәрләрнең әхлакый характеры. Белемнең хезмәт белән бәйләнеше. Намуслылык, гаделлек, юмартлык, сабырлык, яшьтән үк әхлакны тәрбияләү турында әңгәмә.

10.2.6. XIX гасыр татар әдәбияты. XIX гасырда татар әдәбияты үсешенең үзенчәлекләре. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Реалистик поэзиянең барлыкка килүе. Әсәрләр тематикасы.

Г. Кандалый иҗаты. «Сахибҗәмал» (өзек). Поэмада бөек мәхәббәт хисләрен данлау. Хатын-кыз матурлыгын тасвирлау. Авторның идея-эстетик табышларының иҗтимагый аң үсеше белән үзара бәйләнеше.

К. Насыйриның тормышы һәм иҗаты. «Кырык бакча». Әхлакый сыйфатлар. Кешенең рухи матурлыгы.

М. Акъегетзадәнең тормышы. «Хисаметдин менла» повесте. Әсәрдә мәгърифәтчелек идеяләре. Заман герое проблемасы. Мәгърифәтчелек реализмы.

10.2.7. XX гасыр башы татар әдәбияты. XX гасыр башы татар әдәбиятының үзенчәлекләре. Татар әдәбиятының Көнчыгыш, рус, Европа әдәбиятларының фәлсәфи һәм мәдәни казанышларына якынаюы.

Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты. «Милләткә», «Милли моңнар» шигырьләре. Үз халкыңа, милләтеңә карата мәхәббәт һәм хөрмәт хисләре. Лирик геройның татар халкы язмышы турында кичерешләренең тирәнлеге. Шагыйрь иҗатында фольклор мотивларының чагылышы.

Дәрдмәнднең тормышы һәм иҗаты. «Видагъ», «Гөрләгән сулар башында» шигырьләре. Ватан темасы.

С. Рәмиевнең тормышы һәм иҗаты. «Таң вакыты», «Мин» шигырьләре. Лирик геройның үз халкы өчен борчылуы, аны иректә, белемле, алдынгы итеп күрү теләге. Романтик геройның үзенчәлекләре.

Г. Исхакыйның тормышы һәм иҗаты. «Сөннәтче бабай» повесте. Татар халкының әхлакый сыйфатлары.

Ф. Әмирханның тормышы һәм иҗаты. «Хәят» әсәре. Матурлык, нәфислек, мәхәббәт культларының консерватив әхлак белән каршылыгы. Төп героиня кичерешләренең тирән лиризмы. Героиняның дөньяга карашын формалаштыруга тирәлекнең йогынтысы. Образлар системасы.

10.1.1. 1920 — 1930 еллар татар әдәбияты. Бу чор татар әдәбиятының үзенчәлекләре.

Х.Такташның тормышы һәм иҗаты. «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы. Әсәр геройларына карата автор позициясе. Автор-ның «ирекле мәхәббәт » идеясенә тискәре мөнәсәбәте.

10.1.2. Бөек Ватан сугышы чоры һәм сугыштан соңгы еллар татар әдәбияты.

М. Җәлилнең тормышы һәм иҗаты. «Моабит дәфтәрләре: «Җырларым», «Кичер, илем» шигырләре. «Моабит дәфтәрләре»нең шагыйрьнең туган ягына кайту тарихы. Батырлык һәм каһарманлык темасы. Лирик геройның хисләре һәм кичерешләре. Шигырьләрендә сәнгати алымнар.

Ф. Кәримнең тормышы һәм иҗаты. «Кыр казы» шигыре. Туган ил, туганнарын һәм якыннарын сагыну, сагыш хисе.

10.1.3. 1960 — 1980 еллар татар прозасы. Әлеге чор татар прозасының үзенчәлекләре.

А. Гыйләҗев, «Өч аршын җир». Кеше характерында милли сыйфатлар, Ватаннан еракта булган кешенең милли характер сыйфатларын сәнгати ачу. Әсәрнең төп героеның характерын ачуда юл хронотобының роле.

10.1.3. 1960 — 1980 еллар татар лирикасы. Әлеге чор татар лирикасының үзенчәлекләре.

Р. Фәйзуллин, «Нюанслар иле: «Чынлык», «Вакыт», «Көзге яңгыр», «Язгы кәеф». Шагыйрьнең вакыт, тарих, тормыш турында фәлсәфи уйланулары.

Р. Харис, «Ак сөлге». Милли традицияләрне саклау проблемасы.

И. Юзеев, «Калдыр, аккош, каурыеңны» шигыре.

10.1.4. 1960 — 1980 еллар татар драматургиясе. Әлеге чор татар драматургиясенең үзенчәлекләре.

Т.Миңнуллин, «Дуслар җыенган җирдә» драмасы. Әсәрдә әхлакый проблемалар.

10.1.5. XX—XXI гасырлар чиге татар әдәбияты. Әлеге чор татар әдәбияты үсешенең үзенчәлекләре.

Р. Миңнуллин, «Һәйкәлләрне тыңлыйк!» Совет халкының батырлыгына һәм каһарманлыгына гимн.

10.1.6 Хәзерге татар әдәбиятының үсешенә күзәтү. Дөньякүләм әдәби процесс. Татар, рус һәм чит ил әдәбияты арасындагы үзара бәйләнешләр.

А.Әхмәтгалиева, «Кайтаваз». Ана белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләр. Кеше тормышында ананың роле.

Р. Мөхәммәтшин, «Күктә кояш балкып-балкып яна», «Август азагы» шигырьләре

10.3. Әдәбият теориясе.

Әдәби процесс, әдәбиятның үсеш этаплары, дини әдәбият, дөньяви әдәбият, дидактизм, хикмәтләр, мәгърифәтчелек реализмы, музыкаль драма, автор позициясе.

## ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

Төп гомуми белем бирү баскычында «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметын өйрәнү укучыларда түбәндәге шәхескә кагылышлы нәтиҗәләрне формалаштырачак:

1) ***гражданлык тәрбиясе:***

гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу, башка кешеләрнең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итү, гаилә, белем бирү оешмасы, җирле берләшмә, туган як, туган ил тормышында актив катнашу, шул исәптән әдәби әсәрләрдә чагылдырылган вакыйгалар белән чагыштыру аша да;

экстремизм, дискриминациянең теләсә кайсы формаларын кабул итмәү, кеше тормышында төрле иҗтимагый институтларның ролен аңлау, гражданның төп хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын, күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә шәхесара мөнәсәбәтләрнең иҗтимагый нормаларын һәм кагыйдәләрен күзаллау, шул исәптән туган (татар) телдәге әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да;

төрле уртак эшчәнлеккә әзер булу, үзара аңлашуга һәм үзара ярдәмләшүгә омтылу, шул исәптән әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да; мәктәп үзидарәсендә актив катнашу, гуманитар эшчәнлектә катнашырга әзер булу;

***2) патриотик тәрбия:***

татар әдәбияты, шулай ук рус әдәбияты әсәрләрен өйрәнү контекстында күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә Россия гражданлыгы тәңгәллеген аңлау, туган телне (татар телен) һәм туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну;

Ватаныбыз Россиянең казанышларына, фәнгә, сәнгатькә, спортка, технологияләргә, халыкның хәрби батырлыкларына һәм хезмәттәге казанышларына, шул исәптән сәнгать әсәрләрендә чагылдырылганнарына да, зур әһәмият бирү;

Россия символларын, дәүләт бәйрәмнәрен, тарихи, табигый мирасны һәм һәйкәлләрне, илебездә яшәүче төрле халыкларның гореф-гадәтләрен хөрмәт итү, аларның татар әдәбиятында чагылдырылуына игътибар бирү;

***3) рухи-әхлакый тәрбия:***

әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын

һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү;

үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу;

җәмгыятьтә кабул ителмәгән гамәлләрне тулысынча кире кагу, шәхси һәм иҗтимагый киңлек шартларында шәхеснең иреге һәм җаваплылык;

***4) эстетик тәрбия:***

үз халкың һәм башка халыклар сәнгатенең барлык төрләрен, традицияләрен һәм иҗатын кабул итү, сәнгатьнең, шул исәптән өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең эмоциональ тәэсирен аңлау;

аралашу һәм үзеңне чагылдыру чарасы буларак матур әдәбият һәм мәдәниятнең мөһимлеген аңлау;

Россия һәм дөнья сәнгатенең кыйммәтен, этник мәдәни традицияләрнең һәм халык иҗатының ролен аңлау;

сәнгатьнең төрле төрләрендә үзеңне чагылдырырга омтылыш;

***5) физик тәрбия, сәламәтлек һәм эмоциональ иминлек культурасын формалаштыру:***

тормыш һәм уку тәҗрибәсенә таянып, тормыш кыйммәтләрен аңлау, үз сәламәтлегенә җаваплы карау һәм сәламәт яшәү рәвеше (сәламәт туклану, гигиена кагыйдәләрен үтәү, дөрес оештырылган эш һәм ял режимы, даими физик активлык) алып бару;

начар гадәтләрнең (спиртлы эчемлекләр, наркотиклар куллану, тәмәке тарту) һәм физик-психик сәламәтлеккә башка зыян салу формаларын аңлау һәм кире кагу, шул исәптән интернет-мохиттә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү:

стресслы ситуацияләргә, үзгәрүчән социаль, информацион һәм табигать шартларына җайлашу, шул исәптән үз тәҗрибәсеннән чыгып һәм алга таба максатлар да куеп, үзеңне һәм башкаларны битәрләми кабул итә белү сәләтенә ия булу;

әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау, үз эмоциональ халәтең белән идарә итә алу осталыгы, рефлексия күнекмәсе формалашкан булу, әдәби геройларның гамәлләрен бәяләү аша үзеңнең, башкаларның хаталану хокукы булуын тану;

***6) хезмәт тәрбиясе:***

технологик һәм социаль юнәлештәге практик мәсьәләләрне (гаилә, мәктәп, шәһәр, төбәк кысаларында) хәл итүдә актив катнашу максатын кую, мондый эшчәнлекне башлап җибәрү, планлаштыру һәм мөстәкыйль башкара алу сәләтенә ия булу;

өйрәнелгән предмет белемнәрен куллануга һәм әдәби әсәрләрдә геройларның эшчәнлеге белән танышуга да нигезләнеп, һөнәрләрне һәм хезмәт төрләрен гамәли яктан өйрәнү белән кызыксыну;

уңышлы һөнәри эшчәнлек өчен гомер буе белем алуның әһәмиятен аңлау һәм моның өчен кирәкле күнекмәләр булдыру һәм үстерү;

һөнәри мохиткә яраклаша белү; хезмәтне һәм хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләрен хөрмәт итү, шул исәптән татар фольклоры һәм әдәбияты әсәрләрен өйрәнгәндә дә, шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрне, ихтыяҗларны исәпкә алып, белем алуның һәм тормыш планнарының индивидуаль траекториясен аңлы рәвештә сайлау һәм төзү;

***7) экологик тәрбия:***

иҗтимагый һәм табигать фәннәреннән алган белемнәрне әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү, гамәлләрне планлаштыру һәм аларның әйләнә-тирә мохит өчен мөмкин булган нәтиҗәләрен бәяләүдә куллануга юнәлдерү;

экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау;

экологик проблемаларны күтәргән әдәби әсәрләр белән танышканда формалашкан карашларга да нигезләнеп, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүче гамәлләрне кире кагу;

табигый, технологик һәм иҗтимагый мохитнең үзара бәйләнеше шартларында гражданин һәм кулланучы буларак үз ролен аңлау, экологик юнәлештәге практик эшчәнлектә катнашырга әзер булу;

***8) фәнни танып белү кыйммәтләре:***

үз эшчәнлегендә кеше, табигать һәм җәмгыять үсешенең төп закончалыклары, кешенең табигый һәм иҗтимагый мохит белән үзара бәйләнешләре турындагы фәнни күзаллауларның заманча системасына юнәлгәнлек;

дөньяны танып белү чарасы буларак, тел һәм уку культурасына ия булу;

әдәби белем үзенчәлекләрен исәпкә алып, тикшеренү эшчәнлегенең төп күнекмәләрен үзләштерү, тәҗрибә, күзәтү, эш-гамәлләрне аңлауга юнәлгәнлек һәм шәхси, коллектив иминлеккә ирешү юлларын камилләштерү омтылышына ия булу;

***9) укучының үзгәрүчән социаль һәм табигый мохит шартларына яраклашуын тәэмин итү:***

укучыларның социаль тәҗрибәне, үз яшенең төп эшчәнлегенә туры килә торган иҗтимагый рольләрне, тәртип, нормаларны һәм кагыйдәләрне, төркемнәрдә һәм җәмгы-

ятьтә, шул исәптән гаиләдә, һөнәри эшчәнлек буенча оештырылган төркемнәрдә һәм берләшмәләрдә, шулай ук башка мәдәни мохит кешеләре белән үзара социаль бәйләнеш кысаларында иҗтимагый тормыш формаларын үзләштерүе, әдәби әсәр персонажларының социаль рольләрен өйрәнүе һәм бәяләве;

билгесезлек шартларында үзара бәйләнештә эш итү сәләте, тәҗрибә алырга һәм башкаларның белемнәренә таянырга әзер тору, билгесезлек шартларында эш итә алу сәләтенә ия булу, гамәли эшчәнлек аша үзенең компетентлык дәрәҗәсен күтәрү, шул исәптән башка кешеләрдән өйрәнә алу, уртак эшчәнлектә башкаларның тәҗрибәсеннән яңа белемнәр, күнекмәләр һәм компетенцияләргә төшенү;

образларны ачыклау һәм үзара бәйләү күнекмәсе, яңа белемнәр формалаштыру сәләте, билгеле булган һәм моңа кадәр билгесез объектлар һәм күренешләр турында идеяләр, төшенчәләр, гипотезалар тәгъбирләү, үзендә белем һәм компетенцияләрнең җитенкерәмәвен аңлау, үз үсешен планлаштыру;

тотрыклы үсеш концепциясе өлкәсендә төп төшенчәләр, терминнар һәм күзаллаулар белән эш итә белү;

табигать, җәмгыять һәм икътисадның үзара бәйләнешләрен анализлый һәм ачыклый алу;

әйләнә-тирә мохиткә тәэсирне, максатларга ирешү һәм мөмкин булган каршылыкларны җиңүне, глобаль нәтиҗәләрне исәпкә алып, үз гамәлләрен бәяли алу;

стресслы ситуацияне аңлый, тормыш һәм укучы тәҗрибәсенә таянып, дөньяда бара торган үзгәрешләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бәяли алу, стресслы ситуацияне кире кагарлык чара күрелергә тиешле чакыру буларак кабул итү, стресслы ситуацияне бәяләү, кабул ителгән карарларны һәм гамәлләрне үзгәртү, килеп туган куркынычларны һәм аларның нәтиҗәләрен тәгъбирләү һәм бәяли алу, төрле юлларын эзләү, билгеле бер ситуациянең уңай ягын таба белү, уңышка ышаныч булмаганда да эшләргә әзер тору.

11.2. Төп гомуми белем дәрәҗәсендә туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү нәтиҗәсендә укучыда танып белү универсаль уку гамәлләре, коммуникатив универсаль уку гамәл-

ләре, регулятив универсаль уку гамәлләре, уртак эшчәнлек осталыгы формалаштырылачак.

11.2.1. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге төп логик гамәлләр формалаштырылачак:

объектларның (сәнгати һәм уку текстлары, әдәби геройлар һәм башкалар) һәм күренешләрнең (әдәби юнәлешләр, әдәби-тарихи барыш этаплары) төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү;

классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, аларны гомумиләштерү һәм чагыштыруның нигезен гамәлгә кертү, үткәрелгән анализ критерийларын билгеләү;

тәкъдим ителгән мәсьәләне исәпкә алып, карала торган әдәби фактларда һәм текстны күзәтүләрдә закончалыкларны һәм каршылыкларны ачыклау, аларны ачыклау өчен, критерийлар тәкъдим итү;

куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау;

әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, дедуктив һәм индуктив фикерләүне, охшашлык буенча фикерләүне кулланып нәтиҗәләр чыгару, аларның үзара бәйләнешләре турында гипотезалар тәгъбирләү;

текстларның төрле төрләре белән эшләү барышында уку мәсьәләсен чишү ысулын мөстәкыйль сайлау (чишелешнең берничә вариантын чагыштыру, мөстәкыйль билгеләнгән критерийларны исәпкә алып, иң кулаен табу).

11.2.2. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак укучыда түбәндәге төп тикшеренү гамәлләре формалаштырылачак:

әдәби белем алуда сорауларны танып белүнең тикшеренү коралы буларак куллану;

ситуациянең, объектның реаль һәм кирәкле халәте арасындагы аерманы теркәргә ярдәм иткән сорауларны тәгъбирләү һәм нәрсә бирелгән, нәрсәне эзләп табасы икәнлеген мөстәкыйль билгеләү;

үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү;

әдәбиятта өйрәнү объектының үзенчәлекләрен, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен һәм объектларның үзара бәйлелеген билгеләүдә мөстәкыйль төзелгән план буенча зур булмаган тикшеренү үткәрү;

тикшеренү (эксперимент) барышында алынган мәгълүматның кулланырлык һәм ышанычлы булуына бәя бирү;

үткәрелгән күзәтү, тәҗрибә, тикшеренү нәтиҗәләре буенча гомумиләштерүләрне һәм нәтиҗәләрне мөстәкыйль рәвештә формалаштыру; алынган нәтиҗәләрнең һәм гомумиләштерүләрнең ышанычлылыгын бәяләү коралларына ия булу;

вакыйгаларның алга таба үсешен һәм аларның бердәй яки охшаш ситуацияләрдә нинди нәтиҗәләргә китерәчәген фаразлау, шулай ук аларның яңа шартларда һәм контекстларда, шул исәптән әдәби әсәрләрдә дә үсеше турында фаразлар тәкъдим итү.

11.2.3. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда мәгълүмат белән эш итүнең түбәндәге күнекмәләре формалаштырылачак:

чыганаклардан тәкъдим ителгән уку бурычын һәм бирелгән критерийларны исәпкә алып, әдәби һәм башка төр мәгълүматны эзләү һәм сайлау барышында төрле инструментлар, ысуллар һәм табу алымнарыннан файдалану;

төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү;

төрле мәгълүмат чыганакларында (бер үк идеяне, версияне раслаучы яки кире кагучы) охшаш аргументлар табу;

әдәби һәм башка төр мәгълүматны тәкъдим итүнең оптималь формасын мөстәкыйль рәвештә сайлау һәм гади схемалар, диаграммалар, башка графика һәм аларның комбинацияләре ярдәмендә чишелергә тиешле уку мәсьәләләрен тасвирлап бирү;

әдәби һәм башка төр мәгълүматның ышанычлылыгын укытучы тәкъдим иткән яки мөстәкыйль рәвештә тәгъбир ителгән критерийлар буенча бәяләү;

мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру.

11.2.4. Коммуникатив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге коммуникатив күнекмәләр формалаштырылачак:

фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү, үзеңне (үз фикереңне) телдән һәм язма текстларда белдерү;

аралашуның вербаль булмаган чараларын тану, социаль билгеләрнең мәгънәсен аңлау, конфликтлы ситуацияләрнең алшартларын белү һәм тану, әдәби әсәрләрдә охшашлыклар табып, конфликтлы ситуацияләрне көйләү, сөйләшүләр алып бару;

башка кешеләрнең ниятләрен аңлау, әңгәмәдәшкә ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәтү һәм үзеңнең килешмәгәнлегеңне әдәп белән тәгъбир итү, уку диалогы һәм (яки) дискуссия барышында фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү;

уку мәсьәләсен хәл итүгә юнәлдерелгән идеяләрне җиткерү, аралашуда үзара җылы мөнәсәбәтләрне саклау; үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау;

үткәрелгән тәҗрибә (әдәби эксперимент, тикшеренү, проект) нәтиҗәләрен башкалар алдында тәкъдим итү;

презентация бурычларын һәм аудитория үзенчәлекләрен исәпкә алып, чыгыш форматын мөстәкыйль сайлау, аңа ярашлы иллюстратив материаллар кулланып, телдән һәм язма текстлар төзү.

11.2.5. Регулятив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге үз-үзеңне оештыру күнекмәләре формалаштырылачак:

матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау;

карарлар кабул итүдә төрле алымнарга (индивидуаль, төркемдә карар кабул итү, төркем тарафыннан карарлар кабул итү) юнәлеш тоту;

уку мәсьәләсен (яки аның бер өлешен) чишү алгоритмын мөстәкыйль төзү, булган ресурсларны һәм үз мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку мәсьәләсен чишү ысулын сайлау, тәкъдим ителгән чишелеш вариантларын дәлилләү;

эш-гамәлләр планын (билгеләнгән чишү алгоритмын гамәлгә ашыру планын) төзү, һәм өйрәнелә торган әдәби объект турында яңа белемнәр алуны исәпкә алып, тәкъдим ителгән алгоритмны үзгәртү;

сайлау һәм карар чыгаруда җаваплылыкны үз өстеңә алу.

11.2.6. Регулятив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда үз-үзеңне контрольдә тоту, эмоциональ интеллект, үзеңне кабул итү һәм башкаларны тануда түбәндәге күнекмәләр формалаштырылачак:

әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү;

уку ситуациясенә тиешле бәя бирү һәм аны үзгәртү планын тәкъдим итү;

контекстны исәпкә алу һәм уку мәсьәләсен чишү барышында килеп чыгарга мөмкин кыенлыкларны алдан күрү, чишелешне үзгәрүчән шартларга яраклаштыру;

эшчәнлек нәтиҗәләренә ирешү (ирешмәү) сәбәпләрен исәпкә алу, алган тәҗрибәгә бәя бирү, билгеле бер ситуациядә уңай якны таба белү;

яңа шартлар һәм үзгәрешле ситуацияләр, билгеләнгән хаталар, килеп чыккан кыенлыклар нигезендә эшчәнлеккә төзәтмәләр кертү, нәтиҗәнең максат һәм шартларга туры килүен бәяләү;

башкаларның хисләрен һәм үз хисләреңне аеру, атау һәм алар белән идарә итү;

хисләрнең сәбәпләрен ачыклау һәм анализлау;

матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау;

үз хисләрен белдерү ысулын көйләү;

әдәби геройларның үзара мөнәсәбәтләре турында уйланып, башка кешегә, аның фикеренә аңлы рәвештә карау;

хаталанырга хокукыңны һәм башкаларның да шундый ук хокукын тану;

үзеңне һәм башкаларны гаепләмичә кабул итү;

үзеңә һәм башкаларга карата ачык булу;

тирә-юньдәге бар нәрсәне контрольдә тота алмауны аңлау.

11.2.7. Укучыда уртак эшчәнлекнең түбәндәге күнекмәләре формалаштырылачак:

туган (татар) телдәге әдәбият дәресләрендә конкрет мәсьәләләрне хәл итү барышында командалы (парларда, төркемнәрдә, күмәк) һәм индивидуаль эшнең өстенлекләрен аңлау һәм файдалану, куелган бурычны хәл иткәндә, үзара хезмәттәшлекнең төркем формаларын куллану зарурлыгын аңлау;

бергәләп уку эшчәнлегенең максатын аңлау, аңа ирешүдә күмәк рәвештә гамәлләр булдыру: рольләрне бүлү, килешүләр төзү, бергәләп эшләү барышы һәм аның нәтиҗәсе турында фикер алышу;

берничә кешенең фикерен гомумиләштерә белү, җитәкчелек итүгә, йөкләмәләрне үтәүгә, буйсынуга әзерлек күрсәтү;

туган (татар) телдәге әдәбият дәресендә бергәләп эшне оештыруны планлаштыру, үз ролен билгеләү (аралашуда катнашучыларның теләкләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып), команда әгъзалары арасында бурычларны бүлеп бирү, төркем эшендә (сөйләшү, фикер алышу, «аң штурмы» һәм башкалар) катнашу;

эштә үз өлешеңне башкару, үз юнәлешең буенча сыйфатлы нәтиҗәгә ирешү һәм үз гамәлләреңне команданың башка әгъзалары белән координацияләү;

әдәбият дәресләрендә катнашучылар тарафыннан тәгъбир ителгән критерийларга таянып, гомуми нәтиҗәгә керткән өлешеңнең сыйфатын бәяләү;

нәтиҗәләрне башта куелган бурыч белән һәм һәр команда әгъзасының нәтиҗәләргә ирешүгә керткән өлеше белән чагыштыру, җаваплылык өлкәсе белән уртаклашу һәм төркем алдында хисап бирергә әзерлек күрсәтү.

11.3. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең предмет нәтиҗәләре.

9 нче сыйныфны тәмамлаганда укучы:

*татар телендә белем бирү мәктәпләрендә түбәндәгеләрне өйрәнә:*

әдәби әсәрләрнең эчтәлеген һәм анда күтәрелгән проблемаларны әсәрнең язылу вакыты һәм анда чагылдырылган

чор белән чагыштырырга, тарихи-әдәби процессның төп этапларын аерып күрсәтергә;

язучының биографиясеннән төп фактларны һәм аның иҗатының тарихи-мәдәни чоры турында мәгълүматларны белергә;

сюжет һәм композиция төзелеше, конфликт үзенчәлекләрен характерларга;

әдәби әсәрдә геройларның, хикәяләүчеләрнең позицияләрен ачыкларга һәм аера белергә;

әдәби әсәрне авторның сәнгати фикерләве буларак кабул итәргә, автор позициясен ачыкларга;

әдәби текстны анализлаганда өйрәнелгән әдәби-теоретик төшенчәләрне кулланырга (әдәби процесс, әдәби чорлар, автор позициясе һ. б.);

тәкъдим ителгән әдәби тематика буенча, бер язучының һәм төрле язучыларның бер яки берничә әсәренә таянып, инша язарга;

*рус телендә белем бирү мәктәпләрендә түбәндәгеләрне өйрәнәчәк:*

әдәби әсәрләрнең эчтәлеген һәм анда күтәрелгән проблемаларны әсәрнең язылу вакыты һәм анда чагылдырылган чор белән чагыштырырга, тарихи-әдәби процессның төп этапларын аерып күрсәтергә;

язучының биографиясеннән төп фактларны һәм аның иҗатының тарихи-мәдәни чоры турында мәгълүматларны белергә;

сюжет һәм композиция төзелеше, конфликт үзенчәлекләрен характерларга;

әдәби әсәрдә геройларның, хикәяләүчеләрнең позицияләрен ачыкларга һәм аера белергә;

әдәби әсәрне авторның сәнгати фикерләве буларак кабул итәргә, автор позициясен ачыкларга;

әдәби текстны анализлаганда өйрәнелгән әдәби-теоретик төшенчәләрне кулланырга (әдәби процесс, әдәби чорлар, автор позициясе һ. б.);

тәкъдим ителгән әдәби тематика буенча, бер язучының һәм төрле язучыларның бер яки берничә әсәренә таянып, инша язарга;

# ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ
## 9 сыйныф — 34 сәгать
## (рус телендә белем бирү мәктәпләренә)

| № | Тема | Эчтәлек | Сәгатьләр саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **Кереш** | | | | |
| 1 | Сүз сәнгате буларак әдәбият. Әдәбиятны чорларга бүлү (1 сәгать) | Татар әдәбиятын чорларга бүлү. | 1 | Әңгәмәдә катнашу.<br>Уку әңгәмәсе: тема буенча сорауларга җаваплар, үз фикереңне формалаштыру, башкалар фикерләренең мәгънәсен аңлау.<br>Материалны структуралаштыру, системалаштыру, классификацияләү, гомумиләштерү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| **Татар әдәбияты тарихы** | | | | |
| 2 | Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты (2 сәгать) | «Гакыллылар тыңлар, аңлар, беләр имди...» (Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятына гомуми күзәтү. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Камиллек ирешү җиңелме? (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанында гомумкешелек идеаллары чагылышы) | 1 | поэманың эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укыган әсәрнең темасын, идеясен, проблемаларын ачыклау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, сюжет һәм композиция төзелешендәге үзенчәлекләрне табу, поэманың төп героена бәя бирү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| 3 | XIII — XVгасыр әдәбияты (2 сәгать) | Алтын Урда чоры әдәбияты үзенчәлекләре | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган әсәрләрнең темасын һәм проблемаларын билгеләү, төп фикерен ачыклау, эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру, әсәрләрнең тел үзенчәлекләрен ачыклау һәм аларның әдәби әсәрдәге ролен бәяләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җавап бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| | | Мәхәббәт — иң саф хис (С. Сараи. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасының идея-эстетик эшләнеше) | 1 | |
| 4 | Казан ханлыгы чоры әдәбияты (1 сәгать) | Казан ханлыгы чоры әдәбияты. Кол Шәриф. «Гафил торма» | 1 | Уку: әсәрне сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган әсәрләрнең темасын һәм проблемаларын |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | билгеләү, әсәрләрнең идея эчтәлеген ачыклау, текстның тел үзенчәлекләрен ачыклау, әсәрләрдәге тел-сурәтләү чараларын ачыклау һәм аларның әдәби әсәрдәге ролен бәяләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| 5 | XVII гасыр әдәбияты. (2 сәгать) | XII гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү. | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, текст буенча сораулар төзү, укылган текст буенча әңгәмәдә катнашу, укылган текст эчтәлеге нигезендә үз карашыңны формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның тел үзенчәлекләрен ачыклау, әсәрләрдәге тел-сурәтләү чараларын ачыклау һәм аларның әдәби әсәрдәге ролен бәяләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: хикмәт жанрының үзенчәлекләрен билгеләү |
| | | Әхлак һәр чор өчен олы кыйммәт (М. Колый хикмәтләрендә әхлакый кануннар чагылышы) | 1 | |
| 6 | XVIII гасыр әдәбияты (2 сәгать) | XVIII гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү. | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Энциклопедик мирас калдырган әдип (Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты) | 1 | Уку әңгәмәсе: тема буенча сорауларга җаваплар, тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, укылган текст буенча фикер алышуда катнашу, аның нигезендә үз карашыңны формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, әсәрдән тел-сурәтләү чараларын табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җаваплар бирү |
| 7 | XIX гасыр әдәбияты. Мәгърифәтчелек хәрәкәте (4 сәгать) | XIX гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү. Мәгърифәтчелек хәрәкәте | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: язучының биографиясе белән танышу, әһәмиятле вакыйгаларны билгеләү, тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, укылган әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, текстның эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: сюжет һәм композиция төзелешендәге үзенчәлекләрне тасвирлап бирү, әдәби әсәрдә вакыйгалар үстерелеше этабын табу, әсәрнең төп героена бәя бирү. |
| | | Дөньяви хисләр җырчысы. (Г. Кандалый иҗаты. «Сәхибҗәмал» поэмасы) | 1 | |
| | | Татар халкының олуг шәхесе (Каюм Насыйри эшчәнлеге. «Кырык бакча» хикәяләре | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | XIX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты. Гыйлемлек — бәхет ачкычы (М. Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» повестенда заман герое) | 1 | Текстны сөйләү: план буенча кыскача сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| 8 | XX гасыр башы әдәбияты (9 сәгать) | XX гасыр башы әдәбиятына гомуми күзәтү. | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Язучының биографиясе белән танышу.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, укыган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар, текстның эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әдәби әсәрдә геройларның позицияләрен аеру, укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстtагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| | | «Әйдә, халыкка хезмәткә...» (Г. Тукай эшчәнлеге һәм иҗаты. Милләткә» шигыре) | 1 | |
| | | Гөрләгән сулар ни сөйли? (Дәрдмәнднең (Закир Рәмиевнең) тормышы һәм иҗаты. «Видагъ» шигыре) | 1 | |
| | | Милләтнең таңы кайчан атар? (С. Рәмиев тормышы һәм иҗаты. «Таң вакыты» шигыре) | 1 | |
| | | Хатын-кыз — милли яшәеш сакчысы (Г. Исхакый тормышы һәм иҗаты. «Сөннәтче бабай» хикәясе) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татар тормышын яңарышка әйдәүче әдип (Ф. Әмирхан тормышы һәм иҗаты. «Хәят» повесте) | 1 | Декламацияләү:текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш башкару: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү өчен булган сорауларга телдән җавап бирү. |
| | | Хәятнең гүзәл хәяте. (Ф. Әмирхан тормышы һәм иҗаты. «Хәят» повесте) | 1 | |
| | | Хыял иркендә чәчәк аткан мәхәббәт (М. Фәйзинең «Галиябану» драмасы) | 1 | |
| | | Саф хисләр акчага сатылмый. (М. Фәйзи «Галиябану» драмасы) | 1 | |
| 9 | 1920—1930 еллар әдәбияты (1 сәгать) | 1920 — 1930 еллар әдәбиятына гомуми күзәтү. Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, әдәби әсәрләренең язылу вакыты, аларда сурәтләнгән чор һәм әсәрдә күтәрелгән проблемаларны чагыштыру, әсәрнең төп фикерен ачыклау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, геройга бәя бирү, автор позициясен ачыклау, әсәрдән |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | тел-сурәтләү чараларын табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| 1 | Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты (1941 — 1945 еллар) (2 сәгать) | Бөек Ватан сугышы чоры әдәбиятына гомуми күзәтү. М. Җәлил иҗаты. «Моабит дәфтәрләре»: «Җырларым», шигыре | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Уку: әсәрләрне сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әдәби әсәрләренең язылу вакыты, аларда сурәтләнгән чор һәм әсәрдә күтәрелгән проблемаларны чагыштыру, укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү. |
| | | Шагыйрь һәм яугир язмышы (Ф. Кәрим иҗаты. «Кыр казы» шигыре) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Әдәби әсәрне автор фикерен сәнгатьчә җиткерү буларак кабул итү.<br>Хикәяләү: укылган әсәр эпизодлары һәм өлешләре буенча тасвирлап сөйләү (сүз белән сурәт тудыру).<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җавап бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| 11 | 1960 — 1980 еллар әдәбияты (1 сәгать) | 1960—1980 еллар прозасына гомуми күзәтү | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Әсәрләрне уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Телдән сөйләү өчен тезис план төзү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Проект эше: проект эшен башкару өчен, материал җыю һәм системалаштыру, фикер алышу, проект эшен башкару, телдән чыгыш ясау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү. |
| | | Илгә килгәнне иңең белән күтәр (А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повесте) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 12 | 1960 — 1980 еллар шигърияте (2 сәгать) | 1960—1980 еллар шигъриятенә күзәтү. | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Әсәрләрне уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен күрсәтү.<br>Телдән сөйләү өчен тезис план төзү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү |
| | | Гамьле дөнья тудырган хисләр ташкыны (Р. Фәйзуллинның «Нюанслар иле»: «Чынлык», «Вакыт» «Көзге яңгыр» «Язгы кәеф» Р. Харисның «Ак сөлге» шигырьләре) | 1 | |
| 13 | 1960 — 1980 еллар драматургиясе (2 сәгать) | 1960—1980 еллар драматургиясе. Туфан Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» драмасы | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Әкият эченә яшерелгән хакыйкать (Т. Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» драмасында җәмгыятькә тәнкыйди караш) | 1 | геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын күрсәтү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әңгәмәдә катнашу |
| 14 | XX гасыр ахыры — XXI гасыр башында татар әдәбияты (1 сәгать) | Янып калсын гомерең маяк булып... *М. Җәлил* (Р. Миңнуллинның «Һәйкәлләрне тыңлыйк!» шигыре) | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын күрсәтү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әңгәмәдә катнашу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү. |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 15 | Хәзерге татар әдәбияты (1сәгать) | А. Әхмәтгалиева, «Кайтаваз» хикәясе. | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укыган әсәрнең сюжетын темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү. |
| 16 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау.<br>Контроль эш. Нәтиҗәләр чыгару | 1 | Комплекслы кабатлау.<br>Гомумиләштерү, сорауларга җавап бирү.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү. |

## 9 сыйныф — 34 сәгать
## (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)

| № | Тема | Эчтәлек | Сәгатьләр саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **Кереш** | | | | |
| 1 | Сүз сәнгате буларак әдәбият. Әдәбиятны чорларга бүлү (1 сәгать) | Татар әдәбиятын чорларга бүлү. | 1 | Әңгәмәдә катнашу.<br>Уку әңгәмәсе: тема буенча сорауларга җаваплар, үз фикереңне формалаштыру, башкалар фикерләренең мәгънәсен аңлау.<br>Материалны структуралаштыру, системалаштыру, классификацияләү, гомумиләштерү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| **Татар әдәбияты тарихы** | | | | |
| 2 | Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты (2 сәгать) | «Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди...» (Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятына гомуми күзәтү. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Камиллек ирешү җиңелме? (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанында гомумкешелек идеаллары чагылышы) | 1 | поэманың эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укыган әсәрнең темасын, идеясен, проблемаларын ачыклау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, сюжет һәм композиция төзелешендәге үзенчәлекләрне табу, поэманың төп героена бәя бирү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| 3 | XIII — XVгасыр әдәбияты (2 сәгать) | Алтын Урда чоры әдәбияты үзенчәлекләре | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган әсәрләрнең темасын һәм проблемаларын билгеләү, төп фикерен ачыклау, эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру, әсәрләрнең тел үзенчәлекләрен ачыклау һәм аларның әдәби әсәрдәге ролен бәяләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җавап бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| | | Мәхәббәт — иң саф хис (С. Сараи. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасының идея-эстетик эшләнеше) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Казан ханлыгы чоры әдәбияты (1 сәгать ) | Казан ханлыгы чоры әдәбияты. Кол Шәриф. «Гафил торма» | 1 | Уку: әсәрне сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган әсәрләрнең темасын һәм проблемаларын билгеләү, әсәрләрнең идея эчтәлеген ачыклау, текстның тел үзенчәлекләрен ачыклау, әсәрләрдәге тел-сурәтләү чараларын ачыклау һәм аларның әдәби әсәрдәге ролен бәяләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| 5 | XVII гасыр әдәбияты. (2 сәгать) | XII гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү. | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, текст буенча сораулар төзү, укылган текст буенча әңгәмәдә катнашу, укылган текст эчтәлеге нигезендә үз карашыңны формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның тел үзенчәлекләрен ачыклау, әсәрләрдәге тел-сурәтләү чараларын ачыклау һәм аларның әдәби әсәрдәге ролен бәяләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: хикмәт жанрының үзенчәлекләрен билгеләү |
| | | Әхлак һәр чор өчен олы кыйммәт (М. Колый хикмәтләрендә әхлакый кануннар чагылышы) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 6 | XVIII гасыр әдәбияты (2 сәгать) | XVIII гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү. | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тема буенча сорауларга җаваплар, тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, укылган текст буенча фикер алышуда катнашу, аның нигезендә үз карашыңны формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, әсәрдән тел-сурәтләү чараларын табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Энциклопедик мирас калдырган әдип (Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты) | 1 | |
| 7 | XIX гасыр әдәбияты. Мәгърифәтчелек хәрәкәте (4 сәгать) | XIX гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү. Мәгърифәтчелек хәрәкәте | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: язучының биографиясе белән танышу, әһәмиятле вакыйгаларны билгеләү, тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, укылган әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, текстның эчтәлеге һәм формасы |
| | | Дөньяви хисләр җырчысы. (Г. Кандалый иҗаты. «Сәхибҗәмал» поэмасы) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татар халкының олуг шәхесе (Каюм Насыйри эшчәнлеге. «Кырык бакча» хикәяләре | 1 | белән бәйле сораулар формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: сюжет һәм композиция төзелешендәге үзенчәлекләрне тасвирлап бирү, әдәби әсәрдә вакыйгалар үстерелеше этабын табу, әсәрнең төп героена бәя бирү.<br>Текстны сөйләү: план буенча кыскача сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| | | XIX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты. Гыйлемлек — бәхет ачкычы (М. Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» повестенда заман герое) | 1 | |
| 8 | XX гасыр башы әдәбияты (9 сәгать) | XX гасыр башы әдәбиятына гомуми күзәтү. | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Язучының биографиясе белән танышу.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, укыган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар, текстның эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әдәби әсәрдә геройларның позицияләрен аеру, укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү |
| | | «Әйдә, халыкка хезмәткә…» (Г. Тукай эшчәнлеге һәм иҗаты. Милләткә», «Милли моңнар» шигырьләре) | 1 | |
| | | Гөрләгән сулар ни сөйли? (Дәрдмәнднең (Закир Рәмиевнең) тормышы һәм иҗаты. «Видагъ», Гөрләгән сулар» шигырьләре) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Милләтнең таңы кайчан атар? (С. Рәмиев тормышы һәм иҗаты. «Таң вакыты» «Мин» шигырьләре) | 1 | чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү<br>Декламацияләү:текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш башкару: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү өчен булган сорауларга телдән җавап бирү. |
| | | Хатын-кыз — милли яшәеш сакчысы (Г. Исхакый тормышы һәм иҗаты. «Сөннәтче бабай» хикәясе) | 1 | |
| | | Татар тормышын яңарышка әйдәүче әдип (Ф. Әмирхан тормышы һәм иҗаты. «Хәят» повесте) | 1 | |
| | | Хәятнең гүзәл хәяте. (Ф. Әмирхан тормышы һәм иҗаты. «Хәят» повесте) | 1 | |
| | | Хыял иркендә чәчәк аткан мәхәббәт (М. Фәйзинең «Галиябану» драмасы) | 1 | |
| | | Саф хисләр акчага сатылмый. (М. Фәйзи «Галиябану» драмасы) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9 | 1920—1930 еллар әдәбияты (1 сәгать) | 1920—1930 еллар әдәбиятына гомуми күзәтү. Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, әдәби әсәрләренең язылу вакыты, аларда сурәтләнгән чор һәм әсәрдә күтәрелгән проблемаларны чагыштыру, әсәрнең төп фикерен ачыклау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, геройга бәя бирү, автор позициясен ачыклау, әсәрдән тел-сурәтләү чараларын табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты (1941 — 1945 еллар) (2 сәгать) | Бөек Ватан сугышы чоры әдәбиятына гомуми күзәтү. М. Җәлил иҗаты. «Моабит дәфтәрләре»: «Җырларым», «Кичер, илем» шигырьләре | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Уку: әсәрләрне сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әдәби әсәрләренең язылу вакыты, аларда сурәтләнгән чор һәм әсәрдә күтәрелгән проблемаларны чагыштыру, укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әдәби әсәрне автор фикерен сәнгатьчә җиткерү буларак кабул итү.<br>Хикәяләү: укылган әсәр эпизодлары һәм өлешләре буенча тасвирлап сөйләү (сүз белән сурәт тудыру).<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җавап бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Шагыйрь һәм яугир язмышы (Ф. Кәрим иҗаты. «Кыр казы» шигыре) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 11 | 1960 — 1980 еллар әдәбияты (1 сәгать) | 1960—1980 еллар прозасына гомуми күзәтү | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Әсәрләрне уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын текстан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Телдән сөйләү өчен тезис план төзү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Проект эше: проект эшен башкару өчен, материал җыю һәм системалаштыру, фикер алышу, проект эшен башкару, телдән чыгыш ясау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү. |
| | | Илгә килгәнне иңең белән күтәр (А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повесте) | 1 | |
| 12 | 1960 — 1980 еллар шигърияте (2 сәгать) | 1960 — 1980 еллар шигъриятенә күзәтү. | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Әсәрләрне уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын текстан табу, аларның |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Гамьле дөнья тудырган хисләр ташкыны (Р. Фәйзуллинның «Нюанслар иле»: «Чынлык», «Вакыт» «Көзге яңгыр» «Язгы кәеф» Р. Харисның «Ак сөлге», И. Юзеевның «Калдыр, аккош, каурыеңны» шигырьләре | 1 | мәгънәләрен аңлау һәм teksттагы әһәмиятен күрсәтү.<br>Телдән сөйләү өчен тезис план төзү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү |
| 13 | 1960 — 1980 еллар драматургиясе (2 сәгать) | 1960 — 1980 еллар драматургиясе. Туфан Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» драмасы | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын күрсәтү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әңгәмәдә катнашу |
| | | Әкият эченә яшерелгән хакыйкать (Т. Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» драмасында җәмгыятькә тәнкыйди караш) | 1 | |
| 14 | XX гасыр ахыры — XXI гасыр башында | Янып калсын гомерең маяк булып... *М. Җәлил* (Р. Миңнуллинның «Һәйкәлләрне тыңлыйк!» шигыре) | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | татар әдәбияты (1 сәгать) | | | Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын күрсәтү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әңгәмәдә катнашу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү. |
| 15 | Хәзерге татар әдәбияты (1сәгать) | А. Әхмәтгалиева, «Кайтаваз» хикәясе;<br>Р. Мөхәммәтшин, «Август азагы» «Күктә кояш балкып-балкып яна» шигырьләре | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укыган әсәрнең сюжетын темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү. |
| 16 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау.<br>Контроль эш. Нәтиҗәләр чыгару | 1 | Комплекслы кабатлау.<br>Гомумиләштерү, сорауларга җавап бирү.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү. |

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

9 нчы сыйныф дәреслеге үзенең эчтәлеге белән алдагы еллар дәреслекләреннән нык аерыла. Ул тулы әдәбият тарихын үз эченә ала. Әдәби барышны масштаблы итеп укучыга тәкъдим итә.

Югары сыйныфта укучыларның әдәби белемнәре ягыннан әзерлек дәрәҗәләре зур икәнен исәпкә алып, эшнең күләме дә шактый зур. Дәресләр саны аз булганлыктан, әсәрләрне өйдә укырга туры киләчәк. Әмма Борынгы һәм Урта гасырлар, хәтта XX гасыр башы әдәби әсәрләренең теле дә катлаулы. Шуңа телне авыр аңлый торган балаларга текст белән танышуга да вакыт бүлеп бирергә туры килер.

Ә телне яхшы белүче, төрле бәйгеләргә катнашучы һәм киләчәктә белем алуын шушы юнәлештә дәвам итәргә теләүчеләргә уку әсбабындагы әсәрләр белән танышу да файдалы булыр.

Дәреслектә һәм уку әсбабында да укучы аңламаска мөмкин булган сүзнең гадирәк синонимы җәя эчендә курсив белән күрсәтелде, рус теленә тәрҗемәсе бирелмәде. Дәреслектәге милли-мәдәни һәм тарихи характердагы комментарийлар әдәби әсәрләрне уку барышында тәкъдим ителә. Анда әдәби текстта очрый торган теге яки бу сәбәпләр аркасында укучыларга таныш булмаган аерым сүзләр, милли-мәдәни компонентлы төшенчәләр чагылыш таба. Сүз беренче чиратта архаизмнар, тарихи сүзләр, татар халкының һәм гомумән Россиянең ерак үткәнендә булган төшенчәләр һәм күренешләр турында бара. Комментарийлар укучыларны төрле сәнгать әсәрләре белән таныштыру максатыннан да тәкъдим ителә. Милли-мәдәни компонент дәреслектәге иллюстрацияләрдә сурәтләнгән киемдә, бизәнү әйберләрендә, көнкүрештә, йортларның бизәлешендә, интерьерда чагылыш таба. Ул шулай ук игътибар үзәгенә алынырга тиешле өлкә булып тора.

Сүзләр белән эшләү, сүз байлыгын арттыру максатыннан әдәби текстларда очраган фразеологизмнарга, канатлы сүзләргә, образлы гыйбарәләргә аңлатма махсус рубрикада бирелә. Дәреслектә урын алган рубрикалар белән танышу укучыларның дөньяга карашларын, белемнәрен киңәйтә.

Өстәмә мәгълүмат буларак китерелгән материалны ничек, дәреснең кайсы өлешендә файдалану укытучы ихтыярында. Бу бигрәк тә «Шәхесләребез», «Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан» рубрикаларына, «Бу кызыклы», «Файдалы фикер» тамгасы астында күрсәлгән мәгълүматларга карый.

Зур теманы үзләштерү алдыннан бирелгән сорау өйрәнеләчәк өлкәгә кызыксыну уятуны, укучыны җиңелрәк итеп аңа якынайтуны күздә тота. Теманы өйрәнеп бетергәннән соң куелган сорау укучы үзләштерергә тиешле иң мөһим нәрсәгә игътибарны юнәлтә. «Нәтиҗә ясыйбыз» рубрикасы әлеге мөһим нәрсәне кабат кыскаса гына хәтергә салып куярга ярдәм итә.

Дәреслектәге уку материалы өлешчә видеодәресләр форматында да тәкъдим ителә. 9 нчы сыйныф өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылган видеороликларның эчтәлеге Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә, һәм алар федераль белем бирү программалары нигезендә эшләнгән. Видеодәресләрнең төп максаты — укучыларны яңа материал белән таныштыру, аны презентация яки анимация чаралары ярдәмендә аңлату. Бу видеоязмалардан дәресләрдә дә, дистанцион укытуда укучының материалны мөстәкыйль үзләштерүе барышында да файдаланырга мөмкин. Шулай ук укучылар белән дәрестән тыш эшләгәндә дә, аларны уңышлы кулланып була.

Әлеге видеодәресләр һәм шулай ук туган (татар) телдәге әдәбиятны уку-укыту барышында кулланыла торган норматив документлар, федераль эш программалары, дәреслекләрнең электрон вариантлары, методик әсбаплар, медиаматериаллар, татар балалар әдәбияты антологиясе белән «Мәгърифәт» медиаплатформасында (https://magrifat.antat.ru) танышып була.

Методик ярдәмлектә татар һәм рус телендә белем бирә торган мәктәпләр өчен уртак темалар эчендә зәңгәр төс белән бирелгән өлешләр бары татар телендә белем алучы укучыларга гына карый. Мондый урыннар күп түгел. Дәрестә һәр укучы мөмкинлегеннән һәм әсәрнең күпме өлеше белән таныш булуыннан чыгып эшли. Мәсәлән, геройга бәяләмә бир-

гәндә тел байлыгы җитмәгән укучы аның 2 — 3 сыйфатын атарга мөмкин. Ә әзерлекле укучы аның эш-гамәлләренә бәя биреп, тулы картинаны ача ала. Һәр укытучы укучыларның мөмкинлеген, аларның нәрсәгә сәләтле икәнен үзе белә һәм шул мөмкинлектән, алар үзләштерергә тиешле күләмнән чыгып таләп куя.

Әдәби әсәрне өйрәнгәндә сәнгати алымнарның вазифасын ачыклауга өстенлек бирелсә дә, аның тәрбияви, әхлакый кыйммәтен, чор, халкыбыз, туган җиребез тарихы белән бәйләнешенә, рус һәм башка халыклар әдәбияты үсеше белән булган бәйләнешләргә дә игътибар кимергә тиеш түгел.

## ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕНЕҢ ҮРНӘКЛӘРЕ

Методик ярдәмлектә бирелгән дәрес үрнәкләре укытучыга бары юнәлеш бирү һәм бу дәрестә игътибардан читтә калмаска тиешле төп моментларны искәртүне генә максат итә, ләкин дәрестә әлеге үрнәкләрдәгечә генә эш итеп булмый, чөнки сыйныфтагы укучыларның гомум һәм шәхси мөмкинлекләре исәпкә алынырга тиеш. Әсәрне уку, сүзлек белән эшләү, сорауларга җавап бирү, әңгәмәнең ни рәвешле үткәрелүе укытучы ихтыярында. Өстәмә сорау-биремнәр төзегәндә, әңгәмәне үзе сайлаган темага оештырганда, укытучы үзенең тәҗрибәсенә таяна. Шуңа күрә дәрес үрнәкләрендә бу өлешкә киң тукталмадык.

**Тема:** Татар әдәбиятын чорларга бүлү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну; татар халкының тарихына, язма мирасына сак караш һәм хөрмәт хисенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, уку мәсьәләсен (яки аның бер өлешен) чишү алгоритмын мөстәкыйль төзү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, аларны гомумиләштерү һәм чагыштыруның нигезен гамәлгә кертү, әдәби

күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — сәнгатьнең бер төре буларак әдәбият һәм аның башка сәнгать төрләре арасында үзенчәлеген таныу, «әдәби барыш» төшенчәсен аңлау; татар әдәбияты үсешенең чорларын үзләштерү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Д. М. Абдуллина, Г. Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 5—11.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видиоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.
2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Әлеге дәрес уку елын башлап җибәргәнлектән, төп темага керешкәнче, укытучының балалар белән әңгәмәсе күздә тотыла. Бу урында дәреслек авторларының укучыга мөрәҗәгатен файдаланырга мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта сөйләгәннәргә нигезләнеп, бу дәрестә бай язма мирасыбызны өйрәнү турында сөйләшәчәкләре ачыклана. Дәреснең төп максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алга таба әдәбият сәнгатьнең бер төре икәнлеген әйтеп, сәнгать төрләре һәм сүз сәнгате булган әдәбиятның башка сәнгать төрләреннән аермалы, үзенчәлекле яклары аңлатыла. Әйтик, *Сәнгать төшенчәсен ничек аңлыйсыз? Нәрсә ул сәнгать? Аның нинди төрләрен беләсез?* дигән сораулар биреп, әңгәмә корырга, презентация ярдәмендә төрле сәнгать әсәрләрен күрсәтергә мөмкин. Укучылар аларның кайсы сәнгать төренә каравын, нинди чаралар (материал, әсбап)

ярдәмендә тудырылуын, тормышны сурәтли алудагы масштаблылыгын, кешегә тәэсирен ачыклап әйтәләр. Соңыннан укытучының тулыландыруы яхшы. Мәсәлән:

— *Рәсем сәнгате нәрсәләр ярдәмендә иҗат ителә?* (Төрле буяулар, пумалалар һ. б.)

— *Ул кешегә ничек тәэсир итә, без аны нинди органнар ярдәмендә кабул итәбез?* (Хисләребезгә тәэсир итә, аерым хатирәләрне уята. Күреп кабул итәбез.)

— *Тормышны нинди масштабта чагылдыра?* (Чикләнгән.)

— *Статик хәлдәме, әллә хәрәкәттә бирәме?* (Статик, туктап калган мизгел рәвешендә бирә һ.б.)

Башка сәнгать чаралары арасында әдәбиятның мөмкинлекләре киңрәк булуы һәм үзенчәлекләре белән таныштырыла. Ул чагыштырулар аша нәтиҗә ясау юлы белән бара. Әдәбият (әдәби әсәр) төрләрен, жанрларын искә төшерәбез.

Әдәбият сүз ярдәмендә иҗат ителә (төзү материалы — сүз). Сүзне тотып, татып карап булмый, аны күреп уку гына төшенчәне аңларга ярдәм итә. Сүзләрне бергә туплау, аерым максатка хезмәт итәрлек, фикер һәм хискә тәэсир ясарлык итеп тезү сәнгать әсәре тудыра. Сүз ярдәмендә тормышның барлык якларын сурәтләргә, кешенең рухи халәтен ачарга, хыялый, фантастик дөнья барлыкка китерергә була.

Әдәбиятның сурәтләү предметы — кеше һәм аның рухи, матди дөньясы, аны әйләндереп алган җиһан (Җир дә, космос та, без күреп белмәгән илаһият дөньясы да).

Әдәби әсәрне язучы иҗат итә, укучы укый. Димәк, иҗатчының дөньяга карашы, сурәтләү объектына мөнәсәбәте белән укучы фикере бер ноктада очраша. Язучы тормышны үз аңы аша уздырып, үзе кабул иткәнчә (күрергә теләгәнчә) тәкъдим итә. Шул ук вакытта кешеләрнең әзерлеге, тормыш тәҗрибәсе һәм тормышка карашы төрле булу һәр укучыга аны үзенчә кабул итү мөмкинлеге бирә. Бер үк әсәр, аның идеясе, геройлары турында төрле фикерләр туарга мөмкин, әмма әдәбият — әдәп чыганагы, ул кешенең хисләрен, зәвыгын тәрбияли, үстерә, гомумкешелек кануннарын гәүдәләндереп, аны гасырдан гасырга, буыннан буынга тапшыра. Аның төп вазифасы һәм әһәмияте дә шунда. Укучылар әдә-

биятның асылын шулай кабул итеп, аны иҗат итүченең дә зыялы, зәвыклы, тормышны, кешенең рухи дөньясын тирәнтен белүче һәм сүзләр ярдәмендә башкаларга җиткерә, кешенең хисләренә тәэсир итә алырлык шәхес булырга тиешлегенә төшенергә тиешләр.

Сүз сәнгате бик борынгыдан килә. Башта ул халык авыз иҗаты, аның төрле жанрлары рәвешендә була, һәм язма әдәбиятка ихтыяҗ җирлегендә туып, хәзер без күргән биеклеккә ирешә. Сүз сәнгате кешенең рухи кичерешләре, акыл эшчәнлеге аша уздырылган яңа бер әдәби дөнья тудыра.

«Дөньяда иң бәхетсез җан иясе — үз халкының рухи-мәдәни хәзинәсенә тамырлары белән ялгана алмаган кеше. Ул — хәтерсез кеше. Өметсез кеше. Имансыз кеше. Чөнки әдәби-мәдәни мирас ул — буыннар хәтере, халык рухы, ул — кешелекнең гасырлардан килгән хыял-өмете, ул — кешегә, ил-көнгә, иң мөкатдәс идеалларга ышаныч гәүдәләнеше», — дип яза язучы, тәнкыйтьче һәм нашир Мөдәррис Вәлиев.

Бу уку елында татар халкының язма мирасы һәм хәзерге әдәбиятыбызның иң яхшы үрнәкләре белән танышачакларын әйтеп, «әдәби барыш (процесс»)  төшенчәсе аңлатыла. Әдәбиятның чорларга бүлеп өйрәнелүенең төп сәбәпләре күрсәтелә. Татар әдәбиятын чорларга бүлү принцибы аңлатыла, әдәби чорларга кыскача бәя бирелә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреснең бу этабында дәреслектәге сорауларга нигезләнергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәреслекнең 10нчы битендәге 7 нче биремне үтәргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: «Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди...» (Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятына гомуми күзәтү. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну; татар халкының тарихын белү, хөрмәт итү, «гаделлек», «намус» төшенчәләрен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, фаразлау; иптәшләренең җавапларын бәяләү; классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — XII гасырда һәм XIII гасырның беренче яртысында әдәбиятка хас үзенчәлекләрне һәм билгеләрне белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 12—38.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү.

2. Дәреслектәге теманы башлап җибәрә торган сорау ярдәмгә килә. *Безгә кадәр мең еллап элек яшәгән бабаларыбызның әдәбияты нинди булган икән соң? Алар нәрсә турында язган, нинди геройлар тудырган, укучыга нинди фикер җиткерергә теләгән икән?*

Әдәбият һәрвакытта да халыкның иҗтимагый-мәдәни үсеш шартлары белән бәйле була. Язучы үз халкының, үз чо-

рының идеалларын гәүдәләндерә. Димәк, алдагы сорауларга җавап табу өчен, тарихка мөрәҗәгать итәргә, аларның нинди шартларда яшәвен, идеаллары нинди булуын ачыкларга кирәклеге аңлашыла. Билгеле, инде әлеге чорда иҗат ителгән һәм безнең көннәргә кадәр сакланып калган бердәнбер ядкәр — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре дә безгә бик күп нәрсәләрне ачарга булышыр.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда сөйләгәннәргә нигезләнеп, дәреснең төп максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Өйрәнелә торган чор Урта гасыр әдәбиятының бер өлеше санала.

XII гасырда һәм XIII гасырның беренче яртысында безнең борынгы бабаларыбызның утрак тормыш белән, шәһәрләр төзеп, югары мәдәнияткә ия булып яшәүләре тарихи фактларга, дәреслек материалына нигезләнеп укучыларга җиткерелә. Бу чор әдәбиятының Болгар чоры әдәбияты дип атап йөртелүе дә әйтелә.

922 елда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителү, камиллек үрнәге булган Коръән китабы, ислам канунары белән якынаю сүз сәнгате үсешендә яңа мөмкинлекләр ачуы, аны яңа сюжет, геройлар, тел-сурәтләү чаралары, фәлсәфи фикер белән баетуы ассызыклана.

«Дини әдәбият», «дөньяви әдәбият» төшенчәләре аңлатыла.

Болгар чорының күренекле әдибе Кол Галинең тормыш юлы һәм аның атаклы «Кыйссаи Йосыф» поэмасының татар халкының тормышында тоткан урыны турында мәгълүмат бирелә. Дәреслектәге материалга таянып, «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Коръәндәге сюжетка нигезләнүе, шул сәбәпле мөселман дөньясында киң таралган сюжет булуын, татарлар яшәгән төбәкләрдә таралышын, фәнни өйрәнелешен дә сөйләп, әсәр белән танышуга күчелә. (Бу мәгълүматны укучыга видеодәресне карау ярдәмендә дә җиткерергә мөмкин. Видеодәрестә укылган өзекне бу дәрестә кулланмый тору отышлырак булыр.)

Поэманың татар халкының мәдәни тормышындагы урынын билгеләп, әдәбият галиме Резеда Ганиева болай дип яза: «Татар халкы өчен Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы бүген дә җан азыгы вазифасын үти. Идел буйларыннан, Кол Гали ватанынынннан — Болгардан искән саба җилләре өченче меңьеллыкта да милләтебезнең рухи дөньясын сафландыруга хезмәт итә».

Әсәрнең халык арасында киң таралуы, көйләп укылуын истә тотып, түбәндәге QR-код белән кереп, Идрис Газиев башкаруында өзек тыңлап китәргә мөмкин.

Алга таба поэманың бер өлеше сыйныфта укыла (Б. 20 — 26. «Зөләйханың төше» бүлегенә кадәр алырга мөмкин. Бу — дәрес вакытына күпме сыешу белән бәйле).

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслекнең 15 — 16 нчы битендәге сораулар һәм биремнәргә нигезләнергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәреслекнең 16 нчы битендәге 10 нчы биремне үтәргә, сорауларга җаваплар әзерләргә.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын укып килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Камиллеккә ирешү җиңелме? (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанында гомумкешелек идеаллары чагылышы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү; күркәм сыйфатларга, камил холыкка ия булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, фаразлау, әдәби геройларның үзара мөнәсәбәтләре турында уйланып, башка кешегә, аның фикеренә аңлы рәвештә ка-

рау, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, уку диалогы һәм фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү.

*Предмет нәтиҗәләр* — әсәрнең темасын, идея-проблемасын аңлау; композицион төзелешендәге үзенчәлекләрне табу, геройларга бәя бирү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 12—38.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшләрен тикшерү.

2. Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятында билгеле булган сюжетка нигезләнеп әсәр иҗат итү киң таралган була. Коръән китабын иҗатта үрнәк итү дә — шуның бер мисалы (бу урында ияреп язу, назыйрәчелек турында әйтеп үтү, аның плагиат түгеллеген аңлату мәслихәт). Йосыф язмышын сурәтләгән язмалар да бик борынгы чорларда ук очрый. Коръән китабында да әлеге сюжет шактый тулы итеп сөйләнелә. X—XV гасырларда Йосыф — Зөләйха темасына күп әдипләр мөрәҗәгать итә. Кол Гали дә, билгеле сюжетка ияреп, Коръән фәлсәфәсен үзәккә алып, идея-эстетик яктан мөстәкыйль кыйммәткә ия булган әсәр иҗат итә.

Поэма Коръәннең 12 нче сүрәсенә нигезләнә, андагы вакыйгаларны киңәйтә, дөньяви фәлсәфә белән баета. *Автор укучысына нәрсә җиткерергә тели соң? Нинди максат куя?* дигән сорау белән укучыларны уйландырабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сораулардан чыгып, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әсәрне өйдә укып килгән татар телендә белем алучы укучылар белән анализга күчелә. Рус телендә белем алучы укучылар белән әсәрне укып, укылган өлешнең фикере ачыкланып барыла, ахырдан нәтиҗәләр ясала.

Авторның максаты нәрсә дигән сорауга әсәрнең башлам өлешендә җавап табыла:

*Куәт бир син хикмәт юлыннан барырга,*
***Гакыллы колларның күңелен баетырга,***
*Йосыф пәйгамбәр хәлен сөйләп аңлатырга, —*
*Гыйльмем камил, сүзем матур булсын имди.*

Кол Гали нәрсә белән баетырга тели икән кешеләрнең күңелен?

Сюжеттагы ике юнәлеш билгеләтеп куела: Йосыф һәм Зөләйха тарихы мәхәббәт белән берләштерелә.

Йосыф турында сөйләшү дәвам ителә һәм аның белән бәйләнешле вакыйгаларга бәя бирелә һәм нәтиҗә ясап барыла. Йосыф язмышы белән бәйле сюжет сызыгы әсәрдәге вакыйгаларны бергә туплап тора.

Кыйссадагы вакыйгаларның күбесе ялгышу — аның өчен җәза алу — гафу үтенү — гафу ителү калыбына салынган. Укучылар һәркемнең кылган ялгышын һәм алган җәзасын күрсәтә:

Йосыфның агалары → *хатасы*: Йосыфны коега салалар, кол итеп саталар → *җәзасы:* ачлык килә.

Кылыч → *хатасы*: Йосыфны кыйный → *җәзасы:* табигатьтә каты давыл куба.

Йосыф → *хатасы*: үзенең матурлыгы белән тәкәбберләнә, үзен башкалардан өстен күрә → *җәзасы: юлында аннан* матуррак затлар яши торган шәһәргә очрый.

Зөләйха → *хатасы*: Йосыфны азгынлыкта гаепли → *җәзасы:* байлыгын, матурлыгын югалта.

Мисыр хатыннары → *хаталары*: Зөләйханың гайбәтен сөйлиләр → *җәзасы:* әфлисун урынына үз бармакларын кисәләр. Дәреслектә булмаган тагын бер хатаны искәртү кирәк.

Йагкуб, Йосыфның анасы үлгәч, аны имезүче хатынны үз баласыннан аера. Моны ул Йосыфка сөт күбрәк булсын өчен эшли. Баласыннан аерылган ана бик зур хәсрәтле була. Соңыннан Йагкуб та үзенең сөекле улы Йосыфтан аерылырга һәм күп газаплар кичеререргә мәҗбүр ителә.

Поэма геройлары һәркайсы ялгыша, яман гамәл кыла, тәүбәгә килеп гафу үтенә. *Ни өчен автор геройларын шундый язмышлы итеп сурәтли дип уйлыйсыз? Аларны хаталанырга нинди сыйфатлары этәрә?* Йагъкуб, Йосыфның агалары, Зөләйханың ялгышына нәрсә сәбәп булуы аерып күрсәтелә. Үз мәнфәгатьләреңне башкаларныкыннан өстен кую, хисләрнең акылга буйсынмавы, һәр гамәлең өчен үзең үк җавап тотасыңны уйламау һ.б. Укучыларның җавапларыннан соң нәтиҗә ясала: җәмгыятьтә һәм кешеләр арасында килеп туган каршылыкларның сәбәбен автор шулар аша аңлата.

Кеше ялгыша, әмма хатасын танырга, тәүбәгә килергә тиеш, дигән идея үткәрелә. Поэмада Йагкуб, үз улына яхшырак булсын өчен, имезүче хатынны баласыннан аера. Димәк, кеше хәсрәте белән исәпләшми, үзенекен өстен куя. Йосыф агалары туганыннан көнләшәләр, мал өчен туганны үтерүдән дә курыкмыйлар. Зөләйха мәхәббәттә азгынлыкка омтыла. Үз рәхәте өчен башкаларны рәнҗетергә дә мөмкин дип саный. Димәк, автор, башкалар хәсрәте белән бәхетле булырга омтылу, кеше хәсрәтенә битарафлык, шәфкатьсезлек, мал өчен туганны үтерү, ялган, сабырсызлык җәмгыятьне дә, кешеләрне дә бәхетсезлеккә илтә, дип раслый.

Йосыф начарлык кылмый, әмма күп авырлыклар кичерә. Йосыф ни өчен авырлыкларга дучар була? Автор нәрсә әйтергә тели?

Автор ата кылган гөнаһның бала язмышында чагылыш табуын күрсәтергә тели. Йосыфның этисеннән аерылуы да — этисе гөнаһының нәтиҗәсе. Алла тарафыннан җибәрелгән сынауларны кешелеклелеген саклаган хәлдә үтә алуы Йосыфка максатына ирешергә ярдәм итә. Автор гөнаһлар кылудан сак булырга, килгән авырлыкларны сабырлык белән үткәрә белергә куша. Бу фикер әсәрнең Коръән сюжетына бәйлелеге белән аңлатыла.

Коръәндәге «һәркем үз кылган гамәл өчен үзе җавап тота, яхшылык яхшылык булып, яманлык яманлык булып үзенә кайта» дигән идея дә әсәрдә үз көчендә кала. Кешеләр, туганнар арасындагы көнчелек, хөсетлек, сүз йөртү, шәфкатьсезлек, ялганның яманлыкка китерүе ачыла. Явызлык кылганнар үз җәзасын ала. Моның белән автор җәмгыятьтә һәркем өчен яшәеш, әхлак кануннарының бердәй булуын раслый. Һәркем үзе кылган гамәл өчен җавап тота, пәйгамбәрләр дә, илбашлары да, гади кешеләр дә хакыйкать каршысында тигез.

Яманлыкка яманлык белән җавап бирү аны тагын да үстерә, зурайта. Яманлык кылганнарны гафу итү шәфкатьлелек сорый. Йосыф шул шәфкатьлелеккә ия, шуның ярдәмендә ул үзе дә бәхеткә ирешә, явызлыкның таралуына да юл куймый. Әсәр ахырында аның «Әмин», ягъни «имин», «тату» дип аталган дәүләт төзүен күрәбез. Димәк, әсәр шәфкатьлелек һәм татулыкны кешелекнең асылы буларак тәкъдим итә. Автор фикеренчә, яшәешнең иминлеге, бәхетнең нигезе — татулыкта, кешелекле мөнәсәбәтләрдә.

Автор Йосыфны пәйгамбәр дип күрсәтә һәм анда камил инсан (*кеше*) образын гәүдәләндерә. Ул аның нинди сыйфатларга ия булуын әйтә. (Бу урында видеодәрестә бирелгән өзекне тыңларга һәм кешегә хас күркәм сыйфатлар турында сөйләшү үткәрергә мөмкин.)

Дәреслекнең 29 нчы битендәге рәсемгә игътибарны юнәлтеп, аның сюжетның кайсы өлешен сурәтләве ачыклана. Әсәрдән шул өзек укытыла һәм сөйләтелә, аның мәгънәсе ачыклана: Җир йөзендә Кеше — иң зур кыйммәт, аны дөнья малына алыштыру, аның аша бәяләү мөмкин түгел.

Поэмада «матурлык» төшенчәсенә аерым урын бирелгән. Кешеләрне сокландырган, күңелләрне хушландырган нәрсә матурлык була. Димәк, шәфкатьлелек тә, мәхәббәт тә, тугрылык та, сабырлык та матурлык дип аталырга хаклы.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре сәнгати эшләнеше ягыннан искиткеч камиллеккә ия. Фикерен укучыга җиткерүдә ул төрле алымнарга мөрәҗәгать итә, кабатлауларга аеруча игътибар бирә. Ул тулы вакыйгаларны кабатлый: төш күрү-төш юрау, сарай салдыру, хата кылу-гафу үтенү

кебек вакыйгалар. Төш укучыга геройларның язмышын алдан хәбәр итә. Сарайлардагы сурәтләр тел белән әйтә алмаган дөреслекне сөйләп бирә, хата кылу һәм гафу үтенү вакыйгалары кешегә хатасын тану тиеш дигән фикерне кат-кат раслый.

Әсәрдә Йосыф һәм Зөләйханың матурлыгын, Зөләйханың Йосыфка мәхәббәтенең зурлыгын, үзенчәлекле сурәт чаралары ярдәмендә ача, чиктән тыш арттыру (гипербола) дәрәҗәсенә җиткерә. Зөләйха мәхәббәттән авыруга сабыша, башка бернәрсә дә уйлый алмый, инде картайгач та, Йосыф кулындагы камчыга сулышын өрүгә ут каба. Йосыфта иң көчле хис — хакыйкатькә, Аллаһка, иманга һәм этисенә тугрылык. Ул һәр гамәлен Алла канунына, ягъни бердәнбер хакыйкатькә буйсындыра.

Кол Гали, поэма геройларын тасвирлаганда, гадәттән тыш арттыруларны иркен куллана, аларны әкияти вакыйгалар аша ача. Йосыфның Җәбраил фәрештә белән аралашуы, Зөләйханың кабат яшәрүе, хайваннарның телгә килүе әкияти алымнар файдалануын, шул чор мифологик ышануларына таянуын күрсәтә. Кол Гали әсәрендә вакыт, урын төгәллеген бирүне максат итми. Үзенең әсәренең идея кыйммәтен мәңгелек белән тоташтырып куярга омтыла.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре шул чор иҗат кануннарына нигезләнгән. Башлам өлешендә, төп вакыйганы хикәяләүгә күчкәнче, Аллаһка, пәйгамбәрләргә мактау, олылау сүзләрен җиткерә. Алга таба үзенең иҗатына илһам зиһен, ярдәм, куәт сорап, Аллаһка мөрәҗәгать итә. Хәтимә (йомгаклау) өлешендә иҗатына илһам биргән Алласына шөкер кыла, әсәрне кем һәм кайчан язу турында белдерә, укучыга файдалы булуын тели. Акыллы укучының һичшиксез аннан гыйбрәт алачагына ышана:

*Гәүһәр — таш ул, ләкин һәр таш гәүһәр булмас,*
*Тикмә кеше гәүһәр кадрен аңлый алмас,*
*Бу нәзымның кадрен һич ахмак белмәс —*
*Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди.*

Кол Гали үзенең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында кешеләр күңелендә яшәгән иң изге, тормышчан, дөньяви уйларны сүз

дигән тылсымлы да, кодрәтле дә бизәкләргә төреп үлемсез итә алган.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектәге сорауларга нигезләнергә мөмкин. Әсәрнең төзелешен, идея эчтәлеген хәтердә калдырырга тиешләр.

**VI. Өй эше бирү.**

«Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә камил шәхес үрнәге» дигән темага инша язарга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Укытучыга өстәмә мәгълүмат:**

XIII—XIV гасырлар төрки халыклар әдәби үсешендә Яңарыш (Ренессанс) чоры буларак мәгълүм. Яңарыш кичерүче әдәбиятка түбәндәге билгеләр хас:

- гадәти булмаган, фаҗигалы язмышка ия шәхесләрне әсәр үзәгенә куя, илаһи сыйфатлары эш-гамәлләрдә, холык-фигыльдә күренә торган затлы кеше идеалы тудырыла;
- әдәбиятның максаты — яхшылыкны, гүзәллекне күрсәтү ярдәмендә укучыга тәэсир итү, камилләшүгә омтылыш уяту буларак билгеләнә;
- дини (ислам) һәм дөньяви мотивларның тоташуы күзәтелә. Дөньяви мотивлардан гадел идарәче, гафу итү, саф мәхәббәт әһәмиятле урын тота;
- кешенең үз мәнфәгатьләре өчен түгел, җәмгыять, халык, кешелек дөньясы гаме белән яшәве ассызыклана. Үз тормышындагы авырлыкларны җиңеп, кеше тормыш законнарын таба. Яшәү мәгънәсен, максатын эзләү ике нәтиҗәгә китерә: кешенең үз-үзен үзгәртүе һәм кешелекне үзгәртү;
- төрле жанрлар берлеге: фольклордан килгән елау-сыктаулар, шәһәр төзелешен мактаулар, мөнәҗәт, бәет әсәр тукымасында урын ала;
- абстракт сурәт төзүгә омтылу, ягъни кеше тормышында, табигатьтәге үзгәрешләрдә, тарихи вакыйгаларда югарыдан килә торган, язмыш белән бәйле билгеләр күрү, символлар ярдәмендә гадәти детальләргә фәлсәфи эчтәлек салу.

Кол Гали «Кыйссаи Йосыф» әсәре белән әлеге Яңарыш әдәбиятына нигез сала. Бу, иң элек, катлаулы язмышлы затлы кеше, гадел идарәче идеалы Йосыф образында гәүдәләнеш ала. Автор аны тышкы һәм эчке яктан идеал шәхес буларак тасвирлый. Моны раслау өчен, аны пәйгамбәр нәселеннән итеп күрсәтә. Йосыфның тиңсез акыл иясе булуы, тугрылыгы, мәхәббәттә сафлыгы, әхлакый камиллеге, күркәм сабырлыгы, гаделлеге, кешелеклелеге, тәхеткә утыргач та һәр кешене тигез күрүе поэмада кат-кат искәртелә. Автор камил шәхес һәм хөкемдар образын тудыра.

Йосыф-Зөләйха сюжетына төрле халыкларда, төрле чорларда әсәрләр иҗат ителә. Әлеге сюжетка X—XI гасырларда фарсы шагыйре Фирдәүси поэма яза, XIVгасырда татар әдибе Мәхмүд Болгари, XV гасырда таҗиклардан Җами, үзбәкләрдән Дөрбәк мөрәҗәгать итә. 1919 елда латыш язучысы Ян Райнис пьеса, 1933—1943 елларда немец язучысы Томас Ман дүрт томлык «Йосыф һәм аның туганнары» исемле романын бастыра.

XX гасыр башында татар язучылары Мәҗит Гафури, Кәрим Әмири, Зәйни Шәһиморатов, ә XXI гасыр башында Нурмөхәммәт Хисамов кабат бу сюжетка үз әсәрләрен иҗат итәләр.

Кол Гали — төрки телдә бу сюжетка мөрәҗәгать иткән иң беренче шагыйрь. «Кыйссаи Йосыф» поэмасы — безнең әдәбиятыбыз үсешенә зур этәргеч биргән, язма телебезне үстергән, халыкны рухи яктан баеткан, тәрбияләгән борынгы һәм кыйммәтле ядкәр. Ул татар халкы яшәгән һәр йортта Коръән китабы белән янәшә саклanган, аны көйгә салып, күмәкләп укыганнар, яшь киленнәр, кадерле бүләк итеп, тормыш итәсе йортларына алып барган. Кол Гали әсәре — яхшылыкның яманлыктан өстенлегенә дәлил булып, халкыбызның күңелендә яшәгән, авырлыкны җиңәргә көч биргән китап. Харрас Әюповның шигъри юллары да шул фикерне тагын бер кат раслый:

*Боекларның илдә яшен сөрттең,*
*Телгәләнгән җанны сыйпадың.*
*Куктән иңгән дога урынына*
*Ятладылар «Йосыф китабы»н.*

Бу әсәр әдәбиятыбызның хәзерге телгә бик якын, тәүге ядкәрләренең берсе, беренчесе дияргә мөмкин. XIII гасыр башларында иҗат ителеп, сигез йөз елга якын халкыбызның рухи дөньясын даими баетып килгән «Кыйссаи Йосыф» һаман да халкыбызның рухына ямь биреп торган иң асыл әдәби җәүһәрләрнең берсе булып яши.

**Тема:** Алтын Урда чоры әдәбияты үзенчәлекләре.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау; әңгәмәдә катнашу, уку диалогы һәм фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Алтын Урда чоры әдәбияты турында мәгълүматлы булу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 39—43.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Тарихка нигезләнеп, Идел буе Болгар дәүләтенең нинди дәүләт белән алмашынуы искә төшерелә. Укучыларның

Алтын Урда турында беркадәр мәгълүматлары бар. Бу — тарих дәресләренә һәм алдагы сыйныфта өйрәнелгән «Идегәй» дастанына нигезләнә. Шул максаттан укучылар үз фикерләрен әйтә алалар. *Монгол яулап алулары нәтиҗәсендә барлыкка килгән Алтын Урда дәүләте әдәбияты татар әдәбияты үсешенә ничек йогынты ясарга мөмкин? Бу чорда әдәбиятта нинди үзгәрешләр булган?* кебек сораулар ярдәмендә эшне башлап җибәрәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдан әзерләп, Алтын Урда дәүләте турында киңрәк мәгълүмат бирерлек презентация әзерләп тәкъдим итү яхшы. Алтын Урда дәүләтенең эчке төзелеше һәм анда идарә иткән ханнар турында шактый тулы тарихи күзәтү Риза Фәхреддиннең. «Алтын Урда ханнары» китабында бирелә. Әлеге китаптан алынган өзек белән таныштыру укучыларны теманы яхшырак күзалларга ярдәм итәр.

Китапны түбәндәге QR-код белән кереп укырга мөмкин.

Әлеге чор мәдәниятен һәм әдәбиятын тирәнтен өйрәнүчеләрнең берсе булган әдәбият белгече Хатип Йосыф улы Миңнегулов XIV гасырда яшәгән атаклы шәхесләрдән галим Котбеддин Рази, философ Сәгыддин Тәфзани, табиб Ибне Нәҗам, астроном Камаледдин Төрекмәни, Хафизеддин Бәззази, шагыйрь Әхмәд Хөҗәндиләрне күрсәтә.

Алга таба дәреслек материалы нигезендә Алтын Урда дәүләтендәге иҗтимагый-мәдәни тормыш, бу чорның әдипләре аларның әсәрләрендә күтәрелгән төп мәсьәләләр белән таныштырыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслекнең 50 нче битендәге сорауларга нигезләнергә була.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәрестә өйрәнелгәннәрне кабатлап килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Мәхәббәт — иң саф хис (Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасының идея-эстетик эшләнеше).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау, үз эмоциональ халәтең белән идарә итә алу осталыгы; мәхәббәт хисенең зурлыгын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — С. Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасының эчтәлеген белү, идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 44—52 б.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.
2. *Кеше күңеленнән мәхәббәт хисе югалса нәрсә була?* кебек проблемалы сорау белән укучыларны теманы өйрәнүгә кызыксындыра алабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алтын Урда әдибе Сәйф Сараиның тормышы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирелә. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасы сыйныфта укып анализлана.

Әсәрне укып чыккач, аның сюжеты, төп геройларының язмышы хакында укучылар сөйли.

Укытучы поэма турында өстәмә мәгълүмат белән тулыландыра.

«Сөһәйл вә Гөлдерсен» — Сәйф Сараи иҗат иткән оригиналь әсәр. Ул лиро-эпик поэма жанрына туры килә, анда вакыйгаларны хикәяләү фәлсәфи-лирик уйланулар белән чиратлашып бара.

Автор үзе әсәрен «кыйсса» дип атаган. Галимнәр дастан сюжетының реаль җирлеге булу ихтималлыгын да кире какмый. Автор үзе бу хәлнең «чын» икәнлеген кат-кат искәртә, халык телендә дә әсәр сюжетына охшашлы риваятьләр яши. Аларда егет — Туктамыш хан улы, ә Гөлдерсен Аксак Тимер кызы дип бәян ителә. Риваятьтә сөйләнгәнчә, Аксак Тимер сугышчылары хәзерге Тамерлан станциясе (Чиләбе өлкәсендә мәшһүр «Тамерлан манарасы»да бар) тирәсендә егет белән кызны куып җитәләр. Тигезсез сугышта егет һәлак була. Кыз исә үз-үзен хәнҗәр белән кадап үтерә. Алда телгә алынган манара шушы урында Аксак Тимер тарафыннан салдырылган дип карала. Сәйф Сараи үз әсәренең сюжетын чынбарлыктагы вакыйгага нигезләгән булуы да ихтимал. Дастанның тәүге өлешендәге вакыйгалар да реаль, алар 1387—1388 еллардагы Туктамыш белән Аксак Тимернең Харәзем төбәге өчен алып барган канлы сугышлары турында сөйли.

*Геройлар язмышындагы фаҗиганың сәбәбе нәрсәдә?* (Дастанда егет белән кыз — үзара дошман як вәкилләре.)

*Ни өчен С. Сараи үзенең әсәрендә мәхәббәт геройларын дошман як вәкилләреннән сайлады икән?* («Сөһәйл вә Гөлдерсен» — тугрылыклы мәхәббәтне олылаучы дастан. Автор мәхәббәт хисе өчен киртәләр була алмый дип раслый.)

*Автор ни өчен геройлар язмышын һәлакәт белән тәмамлый?* (Сөһәйл вә Гөлдерсеннең фаҗигалы язмышы шәхси бәхетнең иҗтимагый шартларга да бәйлелеген дәлилли, ул дөньяны золымнардан азат итәргә чакыра. Бу — шагыйрьнең иҗтимагый идеалының гәүдәләнеше дә.)

*Автор нәрсә әйтергә тели, әсәрнең идеясе нинди?* Укучылар җавап бирә, укытучы тулыландыра. Бер-берсен өзелеп сөйгән ике яшь гашыйкның һәлакәте тормыштагы гаделсезлекләргә каршы ризасызлык, нәфрәт булып яңгырый. Мәхәббәт — иң бөек хис, сабырлык, гаделлек, ярдәмчел һәм тугры булганда гына саф мәхәббәтне сакларга мөмкин дигән фикер өстенлек итә. Укучыны имин яшәеш, кешелекле мөнәсәбәтләр хакында уйланырга мәҗбүр итә. Мәхәббәт хисе явызлыкка каршы куела, кан коюларның гайре табигый күренеш икәнлеген, халыклар арасында дуслык, татулык мөнәсәбәтләре урнаштырырга кирәклеген искәртә.

Яңарыш (Ренессанс) дип йөртелгән чорның аерым вәкилләре кебек үк, Сәйф Сараи да кешенең хисләренә хөрмәт белән карый, аның бөеклеген дәлилли.

Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше турында сөйләшү алып барыла. Фикерләр әсәрдән өзекләр белән дәлилләнә.

Автор үз геройларын романтикларча, гадәттән тыш киеренке хәлләрдә тасвирлый. Сөһәйл вә Гөлдерсен — искиткеч гүзәл затлар. Дастан каһарманнарының исемнәре үк игътибарга лаек. Гөлдерсен, «гөл кебек (гөлдәй) матур» дигәнне аңлата, Сөһәйл — күктәге якты йолдызларның берсенең (Каноп, Канопусның) Шәрыктагы атамасы.

Сәйф Сараи үз каһарманнарын гәүдәләндерүдә табигать белән янәшәлекне бик иркен файдалана. Шунда ук бик кызыклы бер факт игътибарга лаек. Иптәш кызлары белән күңел ачып йөрүче Гөлдерсен, әсир төшкән, богаулы Сөһәйлне күреп, аңа таба борыла. Кызның бу хәрәкәтен автор Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүе белән чагыштыра:

*Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли,*
*Җир әйләнгән кебек кояш тирәли.*

Сәйф Сараи үзенең «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәре белән үзенә кадәрге язма мирас тәҗрибәсен куллана, үстерә һәм

үзеннән соң киләчәк әдипләргә җирлек әзерли. Сәйф Сараи әсәрләренең үзәгендә камил кеше образына һәм гадел идарәчегә төп урын бирелә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта дәреслекнең 52 нче битендәге сораулар һәм биремнәргә нигезләнергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Уку әсбабында бирелгән Алтын Урда әдибе Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасыннан өзекне укыгыз. С. Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен», Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрләренә нигезләнеп, «Мәхәббәт явызлык белән янәшә яши алмый» дигән темага чыгыш әзерләгез. Фикерегезне әлеге әсәрләрнең геройлары язмышы аша дәлилләгез.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Казан ханлыгы чоры әдәбияты (Кол Шәриф «Гафил торма»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну; «гаделлек», «намуслылык», «шәфкатьлелек» төшенчәләренең асылын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау; әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — шигырнең эчтәлеген белү, идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары

өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 54—61.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.
2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.
2. Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы, Кремль диварларының рәсемен куеп, әңгәмә корыла, аның борынгы мең яшьлек Казан каласының урыны булуы искәртеп үтелә. *Казанда Кремль диварлары эчендә урнашкан Кол Шәриф мәчете туында ишеткәнегез яки аны күргәнегез бармы? Ни өчен ул Кол Шәриф исемен йөрткәнен беләсезме?* кебек сорауларга укучыларның фикерләре тыңлана.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта сөйләгәннәргә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Казан ханлыгының тарихы, андагы иҗтимагый-мәдәни, сәяси тормышка күзәтү ясала. Казан ханлыгына элгәреге Идел буе Болгар дәүләтенә караган бөтен җирләр һәм анда яшәгән халыклар кергән. Ул көньяк-көнчыгышта Нугай Урдасы, көньякта — Әстерхан (Хаҗитархан) һәм Кырым ханлыклары, көнбатышта Мәскәү дәүләте белән чиктәш булган. Ханлык чорында Идел буе татарларының халык буларак формалашуы тәмамлана, әдәби телебез урнаша. Казан ханлыгы зур мәдәни үсешкә ия дәүләт булып, анда әдәби әсәрләр һәм төрле фәннәрдән дә зур хезмәтләр языла. Әмма аларның күбесе шәһәр яулап алынганда юкка чыга.

Казан ханлыгы чорының күренекле шагыйре Мөхәммәдьяр турында кыскача мәгълүмат биреп китү дә яхшы.

Мөхәммәдьярның туган елын галимнәребез якынча XV йөз ахырларына туры килә дип карый. Әсәрләренә нигезләнеп, аның укымышлы булуын, төрки телләрдән кала, гарәп, фарсы телләрен яхшы белүен күрсәтәләр.

Мөхәммәдьяр — фәлсәфи шагыйрь. Ул яшәешнең асылын аңлап, һәр гамәлнең нәтиҗәсен күзаллап, аңлатып бирә. Яхшылыкның яхшылык китерүен, яманлыктан бары яманлык кына тууын искәртә. Гаделлек, намуслылык, шәфкатьлелекне өстен кую, кеше күңелен гүзәл бакча рәвешендә күрергә теләве, җәмгыятнең иминлеген кешелекле мөнәсәбәтләргә бәйләп аңлатуы аны гумманистик шагыйрь итеп таныта. Казан ханлыгында төрле диннәргә табынучы халыкларның имин яшәвен күреп яшәгән шагыйрь кешеләр арасындагы дини ышанулар төрлелегенә караганда явызлык, күңел каралыгы, нәфескә хуҗа булмау, хыянәтчеллек, хөсет-көнчеллекнең җимергеч көчкә ия икәнлеген дәлилли. Мөхәммәдьяр иҗаты дини карашлы үгет-нәсыйхәт бирүе, суфичыл шигърияткә хас образлары белән үз чорының башка шагыйрьләренә аваздаш.

Дәүләт эшлеклесе, дин башлыгы, шагыйрь Кол Шәриф шәхесе турында мәгълүмат биреп, аның «Гафил торма» шигыренә анализ ясала. Образлар системасында суфичылык чагылышын, Кол Шәрифнең суфичыл шагыйрь булуын билгеләп, бу юнәлеш турында искәртеп, алда әле аны тирәнрәк өйрәнәчәкләре әйтеп үтелә.

Суфичылыкның дини әдәбиятның бер тармагы булуына бәйләп, «дини әдәбият» һәм «дөньяви әдәбият» төшенчәләре аңлатыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектәге сораулар һәм биремнәргә нигезләнеп, Казан ханлыгының югары үсешкә ирешкән дәүләт булып яшәвен укучыларның аңлап калулары кирәк.

**VI. Өй эше бирү.**

Язмышлары Казан ханлыгы белән бәйле булган бер зур тарихи шәхес турында чыгыш ясарга әзерләнергә.

Уку әсбабыннан Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» әсәреннән китерелгән өзекне укырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** XVII гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну; «илаһи мәхәббәт» төшенчәсен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, тәкъдим ителгән мәсьәләне исәпкә алып, карала торган әдәби фактларда һәм текстны күзәтүләрдә закончалыкларны һәм каршылыкларны ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашуда үзара җылы мөнәсәбәтләрне саклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — «суфичыл әдәбият», «хикмәт» жанры төшенчәләрен белү

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 62—69.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.
2. *Казан ханлыгының дәүләт буларак яшәүдән туктавы әдәбиятта нинди үзгәрешләр тудыра? Дәүләтчелеген, күпсанлы зыялыларын югалткан халыкның мәдәнияте үсү-*

*ен дәвам итә алганмы? Әдипләр үз иҗатларына нинди максатлар куярлар?* кебек сораулар белән әңгәмә үткәрелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслектәге материалга нигезләнеп, укытучы XVII гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү ясый.

Үткән гасырлардан килгән әдәби ядкәрләр халык күңелендә кабат яңара. Тарихта калган матур вакытларны, Аксак Тимерне, Алтын Урда ханнарын мактаган дастаннар иҗат ителә. Тарихи бәетләр чыгарыла. Халкыбызның данлы тарихын, батыр затларын, күренеке шәхесләрен искә төшерү милли горурлык тәрбияли, киләчәккә ышаныч уята. Бу чорда ярым тарихи, ярым әдәби әсәрләр язылуы да игътибарга лаек. Аерым әсәрләрдә халыкны сабырлыкка чакыру өстенлек итә. Сабырлык, тормыш сынауларына түзү, матди якны түгел, рухи камиллекне уйлау, Алла кануннарына якынаюга йөз тоту суфичылык юнәлешенең кабат өстенлек алуына китерә.

Әдәбиятта Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорындагы әдәбият традицияләре дәвам ителүгә басым ясала. «Җәмиг эт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә», «Тәварихе Болгария» хезмәтләре иҗат ителү; сәяхәтнамә жанры һәм Казанда китап басу эше барлыкка килү турында мәгълүмат бирелә. Әдипләр Аллага якын булу, сабырлык, югары әхлак, кешелеклелек идеяләрен өстен куялар. Әдәбиятка гади хезмәт кешесен тасвирлау килеп керә.

Суфичыл әдәбият һәм хикмәт жанрының эчтәлеге ачыклана. «Суф» сүзе гарәпчә «йон», «йон тукыма» мәгънәләрен белдерә. Суфилар шундый киемнән йөргәнгә күрә. аларга бу исем бирелгән дип тә аңлаталар. Шәрык дөньясында бу исем еш кына «диндар», «дәрвиш» сүзләре белән мәгънәдәш кулланыла. Безнең җирлектә суфи шагыйрьләрнең электән үк килүе күрсәтелә. Әхмәд Ясәви (XI гасырның икенче яртысы) һәм Сөләйман Бакыргани (XI гасырның икенче яртысы) әсәрләре киң таралган була. Казан ханлыгы җимерелгәч, суфичылыкның һәм суфичылык әдәбиятының көчәюе күзә-

телә. Гади һәм аңлаешлы итеп әйткәндә суфичылык әдәбиятына хас төп сыйфатлар:

— Аллаһны беренчел санау, төп тема буларак, илаһи мәхәббәт темасына мөрәҗәгать итү;

— кешене Аллаһ колы итеп карау, сабырлык, басынкылык, гөнаһлар өчен үзен битәрләү белән тәрбияләү. Кеше өчен төп максат — Аллаһ кушканча яшәү;

— хикәяләүче — моңлы, бәхетсез, зарлы кеше;

— төп идея — дөньядан баш тарту, яшәешнең коллык, ялган оясы булуын раслау;

— символлар (шәм — күбәләк, былбыл — чәчәк һ.б.), төсләр символикасы (мәсәлән, сафлык билгесе булган ак төскә еш мөрәҗәгать итү), яшерен фикер-киная, аллегория зур урын алып тора.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әлеге этап түбәндәге сорауларга җавап бирү рәвешендә үткәрелә ала.

*XVII гасыр әдәбияты ни өчен торгынлык чоры әдәбияты дип атала?*

*Бу чор әдәбиятына нинди үзенчәлекләр хас?*

*Әдипләр нинди идеяләргә өстенлек бирә?*

*Суфичыл эчтәлекле әдәбиятның кабат көчәеп китүенең сәбәпләре нәрсәдә?*

**VI. Өй эше бирү.**

Дәреслекнең 68 нче битендәге 1— 4 нче сорауларга җаваплар әзерләргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Әхлак — һәр чор өчен олы кыйммәт (Мәүла Колый хикмәтләрендә әхлакый кануннар чагылышы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү; сабыр була белүнең әһәмиятен аңлау, нәфеснең зыянлы булуына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау, иптәшләренең җавапларын бәяләү; әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, аралашуда үзара җылы мөнәсәбәтләрне саклау.

*Предмет нәтиҗәләр* идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 64—69.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Кешене бизи торган нинди матур сыйфатларны атый аласыз? Әхлаклы булсын өчен, партадашыңа нинди киңәшләр бирә аласың?* кебек сораулар ярдәмендә сөйләшү үткәрергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әлеге әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

М. Колыйның тормышы һәм иҗаты белән таныштырыла. «Колый» аның Колыев фамилиясеннән түгел, ә Урта гасыр әдәбиятына хас «кол» сүзеннән алынган кушамат, шагыйрьнең үзен «Алла колы» итеп атавы да булырга мөмкин.

Хикмәтләре укып анализлана. Укучылар аларның идея-эчтәлеген, дини-дидактик һәм суфичылык юнәлешендә иҗат

ителүен билгелиләр, образларны табалар, суфичылык әдәбиятына хас образларның мәгънәсен аңлаталар.

«Сабырлык турында»гы хикмәт Коръәннән үк килгән сабырлык сыйфатын мактый. Әмма сабыр итеп, гамәл кылмый тик тору фикерен түгел, ә һәрнәрсәнең үз вакыты булуын, кызулык белән хәл итмәү кирәклеген аңлата. Сабырлык нәфесне тыя белү буларак та аңлашыла:

*Харам ашадың, харам эчтең — тәүбә иткел,*
*Гомерең үтте, никадәр кусаң да җитә алмассың.*

Беренче дүртьюллыкта анафора куллануы да күрсәтеп үтелә.

М. Колый суфи шагыйрь буларак бәяләнсә дә, хикмәтләренең нигезендә әхлакый тәрбия, дөньяви мотивлар бик ачык чагыла. Бу аның, Аллага якын булуның иң ышанычлы юлы — рухи сафлык, диндарлык һәм камиллеккә омтылу дигән караштa торуыннан килә. Шагыйрь, инсафлы, тәрбияле, олыны олылаган, ата-ана кадерен белгән, хезмәт сөйгән, югары әхлакка ия кешеләрне Алла да якын күрә, дигән фикердә тора.

Мәүла Колый хикмәтләрендә үз-үзенә мөрәҗәгать итә, хикмәтләрендәге үгет-нәсыйхәтне үзенә дә юнәлтә, аны үтәүне тиеш дип саный, ягъни аның иҗатында лирик герой гәүдәләнеш ала. Аның лирик — герое ихлас, гадел, кешелекле, ярдәмчел шәхес. Дөнья малына, тән ләззәтләренә кызыкмый: рухын пакьләү, үзен эчке яктан камилләштерү белән шөгыльләнә. Әдип фикер җиткерүдә каршы кую, антитеза алымыннан файдалана. Дөньялыкта кешенең нәфескә бирелүен, әхлак кануннарын онытып эш итүе турында сөйли, мондый гамәлнең дөрес түгеллеген искәртә, тәнкыйтьли. Бу дөньяның фанилыгын онытып, дөнья малы җыеп, нәфесләренә бирелгән кешеләрне Алла каршысына барганда киемсез калып барган кешеләргә тиңли:

*Туным бар, — тип, дөнья тунын кигән кеше,*
*Хак каршында ябынурга туны юкдыр.*

Ата-ана хакын хаклауны һәр кешенең бурычы итеп таный, үз вакытында кадер-хөрмәт күрсәтергә өнди, соңыннан

үкенерлек булмасын, ди. «Ата-ана турында»гы хикмәтендә үзенә мөрәҗәгать итеп:

*Мәүла Колый, атаң-анаң белдең микән?*
*Ризалатып, изгү дога алдың микән?*
*Юкса, фатиха бирмәй анлар китте микән, —*
*Кайда бу көн? Кулдин китде, нитмәк кирәк?— дип яза.*

М. Колый хикмәтләрендә авторның күңел халәте, хис-кичерешләре, тормыш-яшәеш турында фикерләре ачык чагылыш таба. Хикмәтләрендә ул тормышчан образларга мөрәҗәгать итә, чагыштырулар аша нәтиҗә ясый, укучысына үгет-нәсыйхәт бирә.

Дәреслектәге хикмәтләрне өйрәнгәндә, һәркайсында автор әйтергә теләгән фикерне ачыклау һәм нинди чаралар, образлылык аша ирешүен анализлап бару кирәк. Үз вакытында М. Колый әйткән фикерләрнең һич искермичә, бүген дә бик актуаль булуы дәлилләнә. Хәзерге тормышыбыз, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, ата-анага карата хөрмәт күрсәтү (күрсәтмәү очракларын да искә алып) тиешлеген аңлатып, укучыларга тәрбия бирү күздә тотыла. Әхлак кануннары беркайчан да искерми, дигән нәтиҗә ясала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Хикмәт жанры үзенчәлекләрен, Мәүла Колый хикмәтләренең эчтәлеген һәм әхлакый кыйммәтен хәтердә калдыру күздә тотыла.

**VI. Өй эше бирү.**

«М. Колый иҗатында әхлакый мәсьәләләр» дигән темага 2—3 минутлык чыгыш әзерләргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: XVIII гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну; рухи ныклык,

алдагы көнгә ышаныч, иман ныклыгы, әхлакый сәламәтлек, гаделлекнең асылына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен (яки аның бер өлешен) чишү алгоритмын мөстәкыйль төзү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру

*Предмет нәтиҗәләр* — XVIII гасыр әдәбияты турында мәгълүматлы булу, шул чор әдәбиятының үсеш закончалыкларын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 70—72.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Йөз ел, бер гасыр вакыт азмы, күпме? Бу вакыт эчендә җиргә 3—4 яңа буын килә. Ә мәдәни тормышны тергезеп җибәрергә, әдәби мирасны кабат торгызырга бу вакыт җитәме?* дигән сорауларга җавап эзләүдән башлап җибәрергә мөмкин. Кеше гомере өчен бу күп вакыт кебек, әмма мәдәни тормышны кабат торгызу өчен күп тә түгел. Чөнки үткәннәрне бөртекләп җыярга, шулар традициясендә яңаны тудырылык иҗат әһелләре, талантлар, әзерлекле кешеләр үсеп җитәргә, алар үзеннән соң килгәннәрне әзерләргә тиеш, моның өчен матди һәм рухи мөмкинлекләр дә кирәк.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әлеге әңгәмәгә бәйләп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укытучы, дәреслектәге материалга нигезләнеп, XVIII гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү ясый. Интернет материалларын да кулланып, презентация әзерләү дә мөмкин. Укытучы чыгышын видеороликны карау белән бәйләп алып бара ала.

Өстәмә материалга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә була:

XVIII гасыр, бигрәк тә аның беренче яртысы икътисади-сәяси яктан да, рухи яктан да авыр һәм катлаулы чор. Дәүләтчелек бетү, руслаштыру сәясәтенең кырыс чаралары бер яктан рухи төшенкелек тудырса, икенче яктан кискен каршылык баш күтәрүләргә китерә. Таяныр урыны калмаганлыктан, халыкның бер өлеше Казан тирәсеннән ерак-карак китү чарасын күрә. Шулай итеп, читрәк төбәкләрдә яңадан мәдәни-рухи асылны торгызу үзәкләре барлыкка килә.

XVIII гасыр башында хәзерге Татарстанның төрле төбәкләрендә, Саба якларында, Биектауга караган Олы Кавал, Өлә Казаклар авылларында, Әтнә ягында Түбән Бәрәскә, Кышкар мәдрәсәләре булуы билгеле (укучылар әлеге сөйләшүне үз якларының тарихи мәдрәсәләре белән тулыландыра ала). Шөһрәтле татар мәдрәсәләренең берсе Эстәрлебаш авылында 1720 елдан эшли башлый. Аның эшчәнлеге XX гасыр башына кадәр дәвам иткән. Мәдрәсәнең китапханәсе үзенең борынгы кулъязма китаплар байлыгы белән бөтен Русиядә танылган. Бу мәдрәсәдә XIX гасырда Мифтахетдин Акмулла, Шәмсетдин Зәки кебек атаклы шагыйрьләр укый. Танылган мәдәрәсәләрдән Оренбург ягы Каргалы, Түбән Шашы, Байлангар, Саба, Сатыш, Иж-Буби, Шекә, Шыгай, Тайсуган, Бәйрәкә, Тымытык, Олы Мәнгәр һәм башка дистәләгән мәдрәсәләр, шулай ук Казанда Апанаев, Әмирханов һәм башка мәдрәсәләр эшләве мәгълүм.

Мәдрәсәләр ачылу, иске татар, гарәп, фарсы, төрек телләрендәге китапларны укырга өйрәнү, телләр белү, татарларның Урта Азиягә (Бохара, Сәмәрканд), Дагстанга, Төркиягә укырга, Мәккәгә Төркия, Мисыр һ.б. илләр аша хаҗга ба-

рулары аралашу өчен зур булышлык булган. Сәүдәгәрләрнең Кытайга, Урта Азиягә, Якын Көнчыгышка, Һиндстанга йөрүләре милләтнең зыялылыгын, сәләтен торгызуга ярдәм иткән. Бу — рухи ныклык, алдагы көнгә ышаныч, иман ныклыгы биргән. Ислам кануннарын саклау әхлакый сәламәтлек, гаделлек, батырлык, сабырлык, ата-ана, бала-чага, туганнар, милләт, өммәт алдында зур җаваплылык тоярга өйрәткән.

Арулык, пакьлек, халкың өчен җаныңны да кызганмаска, чыдам булырга өндәү, башка төшкән авырлыкларны үзебезнең гөнаһларыбыздан дип күреп, гыйбрәт кылырга чакыру әдәбиятыбызда да төп юнәлеш булган.

Галимнәр XVIII гасырда иҗат иткән ике дистәдән артык татар шагыйре булуын күрсәтәләр. Алар арасында иҗатлары киңрәк сакланган Габди, Габдессәлам Уразмөхәммәд улы, Габдерәхим Утыз Имәни, Габделмәннан Мөслимов, Яхъя бине Сәфәргали кебек шагыйрьләрнең һәм исемнәре билгесез авторларның поэтик әсәрләре бар.

Элеккеге милли мирасларыбыздан «Кыйссаи Йосыф», «Кисекбаш», «Нәһҗел-фәрадис», «Дастаны Җөмҗөмә», «Ләйлә-Мәҗнүн» сюжетына язылган поэтик һәм прозаик әсәләр, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани, Өмми Кәмал, Лотфи, Әтнаш Хафизның «Сираҗел-колуб», Мәүла Колый хикмәтләре кебек бик күп әсәрләр кульязма китаплар рәвешендә таралып укылганнар. Кульязма җыентыклардан фарсы теленнән тәрҗемә ителгән «Мәҗмугыл хикәят» кебек зур җыентык күчермәләре, кечкенә күләмдәге көнчыгыш сюжетларына язылган хикәя җыентыклары таралыш алганы билгеле.

Фарсы теленнән тәрҗемә итеп таралган 200 ләп китап исеме мәгълүм.

Татар авторларыннан Г. Утыз-Имәни, Таҗетдин Ялчыгол, Ишнияз бине Ширнияз, Мөхәммәд Әмин, Исмәгыйль Бикмөхәммәд углы сәяхәтнамәләре, Батырша өндәмәләре, Пугачёв турында язмалары бар.

Татар мәдәнияте тарихында XVIII гасырның икенче яртысында төзелгән календарь үрнәкләре дә игътибарга лаек. Алар гаҗәп күп мәгълүматлар белән баетылган, бер тарихи

белешмәлек кебек. Календарьлар еш кына берничә елга хисапланып төзелгәннәр. Анда, астрономия мәгълүматларына нигезләнеп, Урта Иделдәге Кояш чыгу һәм баю, көн озаю, көн кыскару турындагы язмалар урын ала. Айлар унике исем белән китерелә, гадәттә, һиҗри ел һәм айлар, шәмсия (фарсы) айлары исемнәре, еллар күрсәтелгәндә унике еллык хайван календарь атамалары да еш куела. Унике еллык календарьлар, гадәттә, һәр елның физик үзенчәлекләре тасвирланган тәҗрибәләр, астрология юрамышлары белән баетып биреләләр.

Татар календарьларында ел фасыллары, сезонлы эшләр, кошлар килү-китү, чәчү, көтү керү-чыгу, ярминкәләр, тарихи хроника, медицина һ.б. мәгълүматлар да урын алып, алар тормыш дәреслеге булып тора. Берничә елга гамәл итү өчен кулланма; хәтта ки энциклопедия мисалы.

Фал, төш юрау китаплары тарала. Татар телендә «Йосыф китабы» дигән төш тәгъбиренең XVIII гасыр ахырында күчерелгән кулъязма нөсхәләре саклана. Әлеге китап 1990 елларда йөз меңнәрчә тираж белән кабат нәшер ителә.

XVIII гасырның төп әдипләре турында дәреслек материалына нигезләнеп, мәгълүмат бирелә.

Мәдхия, мәрсияләр, ислам кануннарын аңлаткан күп кенә әсәрләр, пәйгамбәрләр тарихлары, Аллаһының сыйфатламаларын җиткерә торган һәм суфичыл эчтәлекле шигырьләр иҗат ителә.

Иҗтимагый теманы күтәргән әсәрләрдә дә дини мотивлар урын ала һәм, киресенчә, дини эчтәлекле әсәрләрдә дә тормыш чынбарлыгына урын бирелә. Мәсәлән, «Илаһи бәет» исеме белән төрле авторлар язган шигырьләрдә (аларның күбесе лиро-эпик характерда) шундый күренеш белән очрашабыз. Шундый әсәрләрнең берсендә туган җирдән аерылу, чит җирдә күргән авырлыклар, ятим балаларның күз яше сурәтләнә.

Халык кузгалышлары, лирикада батырлык темасын алып керә. Каһарманлык, юлбашчылык олы талант, Алла бүләге буларак бәяләнә. Аллаһ билгеләгән ул кеше иң элек мәрхәмәтлелек һәм шәфкатьлелек белән баетылган итеп күрсәтелә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*XVIII гасыр ни өчен катлаулы чор буларак күзаллана? Бу дәвердә халыкның төп максаты нинди булган дип уйлыйсың? Рухи-мәдәни мирасны торгызуга нәрсәләр ярдәм итә? Татар укучысы нинди китаплар укый? XVIII гасырда иҗат иткән кемнәрне беләсез? Әсәрләрдә нинди төп проблемалар күтәрелә?* кебек сораулар ярдәм итәр.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәреслекнең 80—81 нче битләрендәге 1—3 һәм 8—10 нчы сорауларга җаваплар әзерләргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Энциклопедик мирас калдырган әдип (Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу; кеше тормышында гыйлемнең әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, контекстны исәпкә алу һәм уку мәсьәләсен чишү барышында килеп чыгарга мөмкин кыенлыкларны алдан күрү, чишелешне үзгәрүчән шартларга яраклаштыру,иптәшләренең җавапларын бәяләү; әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, әдәби һәм башка төр мәгълүматның ышанычлылыгын укытучы тәкъдим иткән яки мөстәкыйль рәвештә тәгъбир ителгән критерийлар буенча бәяләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — шигырьләрнең эчтәлеген белү, идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 72—81.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Мәңге яшәү мөмкинме? Мәңге яшәү өчен, нәрсә эшләп була дип уйлыйсың?* кебек сораулар белән әңгәмә үткәрелә. Г. Утыз Имәнинең шигырь юллары бу сорауга җавап буларак тәкъдим ителә:

*Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,*
*Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул.*
*...Килсә дә үлем, галим үлми һаман,*
*Үлеме килгәнче үк үлә надан.*

Әдипнең бөтен гомерен белем алуга багышлап, зур гыйлем иясе булуын һәм шул аңа үлемсезлек китерүен дәлил итеп куярга мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслеккә таянып, укытучы Г. Утыз Имәнинең тормыш юлы һәм киңкырлы эшчәнлеге белән таныштыра. (Видеороликтагы материалны нигез итеп алырга мөмкин.) Дәреслектә тәкъдим ителгән әсәрләре укып анализлана. Дәреснең башында китерелгән шигырь юлларының Г. Утыз Имәнинең «Гыйлемнең өстенлеге турында» шигыреннән икәнлеген искә алып, әсәрнең үзе белән танышыла. Әлеге әсәре Урта Азиядә яшәгән вакытта иҗат ителә. Шигырьдә Г. Утыз Имәнинең

«гыйлем» төшенчәсенә мөнәсәбәте ачыла. Гыйлем — тормышның нигезе. Гыйлемнән башка һөнәр иясе булу да мөмкин түгел:

*Гыйлеме улмайанда (булмаганда) юк дорыр һөнәр*, — ди ул.

Г. Утыз Имәни гыйлем кешеләргә төрле авырлыкларны җиңәргә яшәешнең серләрен ачарга ярдәм итә дип күрсәтә. Ул белемне тормыштагы һәр матди байлыктан, кешеләрнең физик ныклыгыннан, йөз матурлыкларыннан да өстен куя, чөнки боларның барысы да вакытлар үтү белән бетә, югала, белем генә сарыф иткән саен арта бара. Гыйлем бу дөньялыкта гына түгел, бакый дөньяда ахирәттә дә хуҗасына ярдәм итә, чөнки дөньяда гыйлемле булып яшәгән кеше Аллаһ каршысына да якты йөз белән бара.

Алга таба дәреслектәге башка шигырьләргә дә анализ ясала. Идея эчтәлеге, тел сурәтләү чараларына игътибар ителә.

Г. Утыз Имәни — күренекле дин галиме, гарәп телендә генә дә унлап дини фәлсәфи трактаты бар, алар өйрәнелеп, рус теленә тәрҗемә итеп басылып чыккан.

Шигъри әсәрләрендә ул үз чорының вәкиле буларак фикер йөртә, үз заманының каршылыклы фикерләре, әдипнең теләк борчулары, кичерешләре чагылыш таба. Аның иҗаты — һәркемгә тормыш сабагы бирә алырлык гади һәм бөек иҗат. Урта гасырлар әдәбиятын җентекләп өйрәнгән галим Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов бик хаклы рәвештә шундый фикер әйтә: «Утыз Имәни исемен югалтырга ярамый. Аның шәхесен һәм әдәбиятыбызны бизәрлек иҗатын без бүгенге һәм киләчәк буынга танытырга тиеш. Утыз Имәнинең тирән фәлсәфи әсәрләрендәге кайбер юлларны ятлап, муенга бөти итеп тагып йөртерлек. Аның мирасы әдәбиятчылар өчен генә түгел, фәлсәфәчеләр, тарихчылар өчен дә кызыклы. Әмма аның хакында сөйләшүләр галимнәр арасында, тар даирәдә генә калмасын иде: Утыз Имәни исемен матбугатта, телевидениедән ешрак яңгыратырга кирәк. Халкыбыз үзенең улы — нинди фикер иясе барлыгын белергә лаек».

Дәрес ахырында дәреслек материалына нигезләнеп, Урта гасырлар әдәбиятына гомуми йомгак ясала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслекнең 81 нче битендәге 7 нче биремне нигез итеп фикер алышу үткәрелә.

**VI. Өй эше бирү.**

*Г. Утыз Имәни үз замандашында нинди матур сыйфатлар тәрбияләргә, нинди начар сыйфатлардан йөз чөерергә өйрәтә*? Шул хакта чыгыш ясарга әзерләнеп килергә.

Дәрестә укып өлгермәгән шигырьләре калса, аларны укып, фикер алышырга әзерләнергә кушыла.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: XIX гасырның беренче яртысында татар әдәбияты. Мәгърифәтчелек хәрәкәте.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну; мәгърифәтле булу, белем алуның әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, уку мәсьәләсен (яки аның бер өлешен) чишү алгоритмын мөстәкыйль төзү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, аларны гомумиләштерү һәм чагыштыруның нигезен гамәлгә кертү, әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — XIX гасырның беренче яртысында татар әдәбияты турында мәгълүматлы булу; мәгърифәтчелек хәрәкәтенең үзенчәлекләрен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 84—88.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Әдәби үсешне чорларга бүлү искә төшерелә. XIX гасыр әдәби хәрәкәттә яңа чорны башлап җибәрә. *Ни өчен икән?* дигән сорау белән укучыларны яңа теманы өйрәнүгә кызыксындыру уятыла.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслек материалына нигезләнеп, XIX гасырның беренче яртысында иҗтимагый-әдәби хәрәкәткә күзәтү ясала. Укучыга материалны җиткерүдә видеороликны нигез итеп алырга була. XIX йөзнең беренче яртысында мәгърифәтчелек хәрәкәте тууга игътибар юнәлтелә. Бу — XIX гасыр мәгърифәтчелек әдәбиятының нигезен тәшкил итә.

Укытучы алдан лекциянең планын тәкъдим итеп, тиешле урыннарны яздырып бара ала.

**Дәреслеккә өстәмә мәгълумат.**

XIX йөз татар әдәбияты Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәгърифәтчелегенең үзара керешүе, дөньявилык һәм илаһилыкның бергә кушылуы, татар фәлсәфи фикеренең формалашуы, кешелеклелек чагылышының тагын да баеп, көчәеп китүе, милли традицияләрнең кабат яңарышы белән характерлы.

Мәгърифәтчелек хәрәкәте барлыкка килсен өчен, аерым шартлар сорала. Татар мәгърифәтчелек хәрәкәте XVIII йөздәге рус мәгърифәтчелеге белән тыгыз бәйләнгән. XIX гасыр чигендә татарлар да дөньяви фәннәр ирешкән уңышларны үзләштерү юлына баса. Уку йортларында татар телен өйрәтүне кертү милли сөйләмне фән теле буларак үстерүгә, төрле гыйльми өлкәләрдәге белемнәрне үз телебездә халык массаларына якынайтуга мөмкинлек тудыра.

1807 елда Казан университетында Х. Д. Френ тарафыннан ачылган Көнчыгыш телләр кафедрасында башта — татар,

төрек, фарсы, кытай, соңрак хәтта санскрит, монгол телләре дә өйрәтелә. Бу — моңа кадәр дә татарлар өчен үз булган мәдәниятне аның каләм ияләренә, мәгърифәтчеләренә тагын бер адымга якынайта.

Университет галимнәре фәнни белемнәрне таратуда гына түгел, методик-педагогик эшчәнлектә дә зур эш башкаралар: мәктәп программалары, дәреслекләр, методик ярдәмлекләр әзерлиләр. Татар укымышлыларыннан И. Хәлфин (1778—1829), С. Кукляшев (1811—1864), Х. Фәезханов (1828—1866), М. Мәхмүдев (1824—1891), К. Насыйри (1825—1902), Ш. Әхмәров (1853—1900) татар грамматикасы буенча дәреслекләр, сүзлекләр төзү, тәрҗемә эшенә керешәләр.

Нигъмәт Ибраһимов (1778—1818) — XIX гасыр башында Казан университетында белем бирүчеләрнең иң күренеклеләреннән. Ул туган тел һәм әдәбият сөючеләр җәмгыяте оештыра, үзе дә шигырьләр яза, яшь сәнгатькярләр һәм галимнәр тәрбияләү эшенә зур көч куя, илгә атаклы математик Н. И. Лобачевский, танылган язучы С. Т. Аксаков һ. б. могтәбәр шәхесләр үстерүдә катнаша, аларның яраткан остазлары була.

Университетның татар галимнәре арасыннан Мөхәммәтгали Мәхмүдов (1824—1891) эшчәнлеген дә аерып күрсәтергә кирәк. Каллиграфия остасы дәрәҗәсенә күтәрелгән гади крестьян егетенең сәләтен, Казан мәдрәсәсендә укыганда ук, университет галимнәре күреп ала һәм, гарәпчә матур язуына таң калып, тирән белемнәргә иялеген дә искә алып, аны университетка татар, төрек, гарәп телләре укытучысы итеп чакыралар. Ул актив рәвештә тәрҗемәчелек белән шөгыльләнә, фәнни-популяр рисаләләр чыгара, 1857 елда үзенең «Татар телен өйрәнүгә практик кулланма» исемле грамматика дәреслеген бастыра.

Китап сәүдәсе белән кәсеп итүчеләр арткannan-арта. Гасыр дәвамында Людвиг Шевиц, Шаһи Яхин, Фәтхулла Амашев, Рәхимҗан Сәетов, Хөсәен Максудов, Рәхмәтулла Әмирханов, Шәмседдин Хөсәен улы, Фәтхулла һәм Габделкәрим Кәтиевләр, Каюм Насыйри, Фатих Халиди, Шиһаб Рәхмәтуллин, Ибраһим Идрисов һ. б. татар китабын басу һәм халыкка тарату эшенә зур көч куя.

XIX гасыр башында Казанда вакытлы матбугат булдыру өчен тырышлык куела.1808 елда И. И. Запольский беренчеләрдән булып, рус һәм татар телләрендә газета бастыру проектын эшли һәм рус телендә «Казанские известия» исемендә газета чыгаруга рөхсәт ала. Бу — татар вакытлы матбугаты булдыру турында фикергә юл ача.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Алдан тәкъдим ителгән план нигезендә укучыларга сораулар куела. Алар, дәфтәрдәге язмаларга нигезләнеп, җаваплар бирә.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәреслекнең 84 — 88 нче битендәге мәгълүмат белән танышырга, узган материалны кабатлап ныгытып килергә. 88 нче биттәге сораулар һәм биремнәрне үтәргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Дөньяви хисләр җырчысы (Габделҗәббар Кандалый иҗаты. «Сахибҗәмал» поэмасы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу; хатын-кызның матурлыгына соклана белү, аңа хөрмәт хисенең асылына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, фаразлау, әдәби геройларның үзара мөнәсәбәтләре турында уйланып, башка кешегә, аның фикеренә аңлы рәвештә карау, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, уку диалогы һәм фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Кандалый иҗаты турында мәгълүматлы булу; «Сахибҗәмал» поэмасының эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлекләрен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 89—95.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *XIX гасыр әдәбиятында хатын-кыз образы ничек гәүдәләнеш алыр дип уйлыйсыз?* дигән сорау белән беренче кызыксыну уятыла.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрес материалын тәкъдим итүдә видеоролик ярдәмгә килә. Ул Г. Кандалый иҗаты турында кыскача мәгълүмат та бирә. «Сахибҗәмал» поэмасы белән дә беркадәр таныштыра. Видеороликны өзеп торып, кирәкле урында өлешләп тә күрсәтү мөмкин.

Г. Кандалый иҗатын укытучы тулырак анализлый. Шагыйрьнең әдәбиятка алып килгән яңалыгы — яңа тематика, яңа герой. Әдип беренче карауга үтә шәхси, интим тоелган сөю хисен шәхес бәхете, аның бәхеткә хокукы, шуларның һәммәсе аша кешенең җәмгыятьтәге хокуклары, дәрәҗәсе белән бәйләнештә икәнлеген күрсәтә. Г. Кандалыйның әдәбиятка хатын-кыз азатлыгы темасын тәкъдим итүе күрсәтелә. Аның «Сахибҗәмал» поэмасында гына түгел, башка шигырьләрендә дә бу мәсьәлә яктыртыла. Әйтик, иҗаты-

ның чагыштырмача башлангыч чорында ук «Нисъф әл-мөлякат...» шигырендә *«Атаң ятка биргәнне тоймый калма, мәхәббәтсез кешегә «Бармыйм» дигән сүзеңне телдән салма»* дип, кыз баланы үз фикерендә калырга өнди. Соңрак инде хатын-кыз да, ирләр кебек үк, мәхәббәттә тигез хокуклы, шәхси бәхеткә лаек дигән карашын ачык белдереп:

*Разый булып ата-ана,*
*Бирәм дисә ки наданга,*
*Алар ризалыкы өчен*
*Гомерлек хәсрәткә калма, — дип яза.*

Шулай итеп, шагыйрь иргә чыгуда кыз балага ата-ана киңәшенә генә ияреп түгел, бәлки үз хисенә ышанып гамәл кылырга куша, малга кызыгуны исә Алла ихтыярына каршы бару дип бәяли. Шәхси бәхет ул малда түгел, ә чын хистә һәм кеше хисен хөрмәтли белә торган надан булмаган яр белән янәшә яшәүдә дип күрсәтә.

Г. Кандалый иҗатының төп мотивы — сөю хисе, мәхәббәт дип билгеләргә мөмкин. Кешенең сөю хисен иң калку гәүдәләндергән «Фәрхи» поэмасында бу мотив тагын да көчәйтелә төшә:

*Күз-кашыны мәсҗедә михраб идәм,*
*Сурәтенә көзгедик мәхабб идәм!*

Шигырьдә кызның күз-кашын мәчеттәге кыйбла, ягъни табына торган тарафны күрсәтүче урын — михрабка, ә аның сурәтен гадәти күзгә күренми торган серле җиргә (мәхаббка) — иләһи объектка тиңли. Сөйгәнен Алла югарылыгына күтәреп мактау соңрак XX гасыр башы шагыйрьләрендә — С. Рәмиев, Г. Тукай иҗатында традиция буларак дәвам итә.

Сыйныфта «Сахибҗәмал» поэмасы укып анализлана. Әсәрнең гади крестьян кызына булган мәхәббәт хисләрен чагылдыруы белән реалистик әсәр үрнәге булуы дәлилләнә. Поэманың төп идеясе — гыйлемле кеше башкаларны да бәхетле итә ала.

Халык теленнән аерылмаслык дәрәҗәдә гади итеп язылуына, сәнгать чараларына игътибар ителә.

Г. Кандалыйның реалистик әдәбиятка нигез салучы булуы билгеләнә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслекнең 145 нче битендәге сорауларга нигезләнергә мөмкин. Г. Кандалыйның әдәбиятка алып килгән яңалыгын, реалистик әдәбиятка нигез салучыларның берсе булуын һәм гади җир кызын олылавы һәм саф хисләргә өстенлек бирүенә игътибар ителә.

**VI. Өй эше бирү.**

Г. Кандалый иҗаты турында сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Татар халкының олуг шәхесе (Каюм Насыйри эшчәнлеге, «Кырык бакча»дан хикәяләр).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну; үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — К. Насыйри эшчәнлеге турында мәгълүматлы булу; «Кырык бакча»дан хикәяләрнең эчтәлеген белү, идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары

өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 96—102.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. К. Насыйриның «Әбүгалисина» әсәрен искә төшерәбез. Укучыларның К. Насыйри шәхесе турында нәрсәләр белүләре белән кызыксынабыз. Аның музеена виртуаль сәяхәт оештырырга да мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укытучы, дәреслектәге материалга нигезләнеп, К. Насыйриның тормышы һәм эшчәнлеге белән таныштыра. Мәгърифәтче-галим буларак, ул үз халкының тарихы, гореф-гадәтләре белән аеруча тирәнтен кызыксынган, озак еллар дәвамында халык арасында йөреп, Казан шәһәре, үзе туган Зөя өязе авыллары тарихына, Пугачёв восстаниесенә һ. б. вакыйгаларга караган риваять һәм легендаларны җыеп һәм шуларга нигезләнеп, тарихи-этнографик хезмәтләр язган.

Алга таба эшчәнлегенең аерым юнәлешләренә тәфсиллерәк тукталына.

К. Насыйриның «Казан татарларының ышанулары һәм гореф-гадәтләре» мәкаләсе татар фольклорын өйрәнү тарихында беренче махсус фәнни хезмәт итеп саналырга хаклы. Ул татар фольклористикасының мөстәкыйль фән буларак формалашуына нигез сала.

Халык иҗаты материалларын галим туган телебезнең лексик һәм стилистик байлыгын өйрәнү һәм үзләштерү, халыкчан әдәби телгә нигез салу өчен дә ышанычлы чыганак

びуларак карый. Туплаган материалларын шул максаттан файдалана, дәреслекләр, сүзлекләр язуда нигез итеп куллана. Татар теленнән беренче аңлатмалы сүзлекне («Ләһҗәи татари», 2 томда) ул төзи.

Тупланган материалны эшкәртеп, халыкның үзенә кайтарып бирү юнәлешендә эшли: китап итеп бастыра, календарьлар чыгара.

Төрле фәннәрдән терминнарны татар телендә булдыруга зур көч куя, тарих, география, математика, геометриядән дәреслекләр яза.

1880 елда басылган «Кырык бакча» китабын да халык авыз иҗатын үрнәкләре — мәкальләр һәм әйтемнәр белән баета. Акыл һәм тәҗрибә үрнәге булган бу китапта тәрбияви хикәяләр урнаштырыла.

Алга таба К. Насыйриның «Кырык бакча»дан алынган хикәяләрен укып, алардагы төп фикер билгеләнә. Әхлак тәрбиясе бирүгә юнәлтелгән хикәяләр буларак бәяләнә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

К. Насыйри эшчәнлегенең төп юнәлешләре ачыклана, «Кырык бакча» хикәяләрендәге тәрбияви өлешләрен кабат хәтердә яңартырлык сораулар куелып, укучылар нәтиҗә ясый.

**VI. Өй эше бирү.**

Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» әсәрен укып килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: XIX гасырның икенче яртысында мәгърифәтчелек әдәбияты (Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» әсәре).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — уңышлы һөнәри эшчәнлек өчен гомер буе белем алуның әһәмиятен аңлау һәм моның өчен кирәкле күнекмәләр булдыру һәм үстерү; аңбелемгә омтылыш хисе туу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау; әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — XIX гасырның икенче яртысында мәгърифәтчелек әдәбияты турында мәгълүматлы булу; М. Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» әсәре эчтәлеген белү, идея-проблематикасына төшенү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 103—122.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Укучыларның М. Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» әсәре белән танышып килүләрен исәптә тотып, әсәрнең нәрсә турында булуы белән кызыксыныла. Уңай геройларга хас сыйфатлар санап чыгыла.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

«Мәгърифәтчелек әдәбияты», «мәгрифәтчелек реализмы» төшенчәләре аңлатыла. М. Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» әсәреннән мәгрифәтчелек реализмна хас билгеләрне укучылар үзләре табып күрсәтә.

Уңай геройларның гел уңай сыйфатлардан гына торуы ачыклана.

Романның төп герое Хисаметдин — Төркиядә укып кайткан укымышлы, заман яңалыклары белән хәбәрдар, газеталар алдырып алар белән танышып бара, игенчелек хезмәте белән шөгыльләнә, үз өендә яңа ысул белән (җәдитчә) балалар укыта. Тормышын да укымышлы кыз белән бәйли, дуслары да үзе кебек халыкны наданлыктан чыгару, авыр хәлдә калганнарга (Мохтар) дөрес юл күрсәтү белән шөгыльләнәләр.

Хисаметдин янәшәсендә бирелгән һәр персонажга аерым мәгънә салынган. Аларның һәркайсына аерым тукталына.

Мохтар хәер сорашып йөрүче ярлы егеттән үз тырышлыгы белән һөнәр үзләштергән сәүдәгәргә әверелә. Аны Хисаметдин теләнчелектән тыя, хәтта участокка яптыра. Хезмәт белән табылган мал гына кешене алга илткәнлеген аңлата. Мохтар извозчик булып яллана, акча туплый, сәүдәгәр булып, эшләре җайга салынгач, үз акчасына мәдрәсә салдыра, шәкертләргә кирәкле чыгымнарны да үзе түли. Гайса Зурколаков — бакыр мастерское хуҗасы, Әбүзәр Дәүләтгилдиев — дәүләт хезмәткәре (юрист, судья). Хисаметдин үзе — яңа карашлы укытучы. Аларны бер нәрсә — милләтне алга җибәрү теләге берләштерә. Шушы юлда алар хезмәтләрен дә, акчаларын да кызганмыйлар. Автор әлеге геройлар ярдәмендә укучыга үз фикерләрен җиткерә, алар теле белән укучыны уйландырырлык һәм нәтиҗә ясарлык фикерләр әйтә.

Әсәрдәге Хәнифә образы турында укучыларның фикерләре тыңлана, укытучы тарафыннан тулыландырыла.

Хәнифә зифа буйлы, чибәр булу өстенә укымышлы, уңган һәм иң мөһиме — үз бәхете өчен көрәшүче, киләчәге турында тирәнтен фикер йөртергә сәләтле. Укый-яза белүе, тәвәккәллеге һәм сүзендә нык торуы аңа язмышын үзе теләгән юлдан алып барырга ярдәм итә. Әсәрдә хатын-кыз иреге мәсьәләсе Хәнифә образында гәүдәләнә. Муса Акъегет татар әдәбиятында беренчеләрдән булып Хәнифә образында иске гореф-гадәтләрне кире кагып, үз бәхете өчен көрәшкән һәм җиңеп чыккан татар кызын иҗат итә.

*Әсәрдә конфликт кемнәр арасында, ул шәхси конфликт кынамы?* дигән сорау ачыклана.

Беренче карашка конфликт Хисаметдин белән Бикбулат хәзрәт арасында кебек. Авылның карт мулласы Бикбулат хәзрәт аның бу эшенә мөмкин кадәр каршылык күрсәтә. Авыл халкы алдында хурлый, абруен төшерә, надан итеп күрсәтергә, эш-гамәлләрендә кимчелек табып, аларны халык алдында фаш итәргә тели. Шуның белән ул дәрәҗәсен күтәрергә, авыл халкын үзенә каратып, иске тәртипләргә буйсындырып яшәтергә омтыла. Әсәрдә төп конфликт — искелек һәм яңалык көрәше гәүдәләндерелгәнлеге ачыла. Үзенең акылы, гыйлеме, сабырлыгы, уйлап эш итүе нәтиҗәсендә Хисаметдин Бикбулат хәзрәт белән булган бәрелешләрдә җиңеп чыга. Бу конфликт аша автор искелеккә ябышып ятмау, дөньяви белемнәрне үзләштерү кирәклеген дәлилли.

Муса Акъегет, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып, үз заманының әһәмиятле мәсьәләләреннән булган җәдитчелек һәм кадимчелек каршылыгын чагылдырып, киң катлам халыкны белемле итү, хатын кыз иреге, гаилә коруда шәхси теләк, фикери уртаклыкны яклап чыга. Бу мәсьәләләрне хәл итүне автор тормышчан вакыйгалар, реалистик геройлар һәм аларның эш-гамәлләре аша ачып бирә.

*Әсәр геройларының яңалыгы нәрсәдә?* Бу сорау укучыларга әдәбиятка яңа герой килүен ачыкларга ярдәм итә.

Хисаметдин белән Хәнифә икесе дә — укымышлы, искелектән килгән, кеше ирегенә һәм бәхетенә каршы куелган киртәләрне үтә алырлык көчле ихтыярлы, яңа заман геройлары.

*Әсәрдә автор әйтергә теләгән төп фикер — идея нәрсә?* Укучылар зләренең фикерләрен әйтәләр, шуларны бергә туплап, нәтиҗә ясала.

М. Акъегетзадә, милли алгарышны югары әхлаклы, белемле һәм һөнәрле, ирекле шәхес кенә тудыра ала. Моның өчен милләтнең үз укымышлылары, хокук сакчылары, һөнәр ияләре, матди ярдәм итәрлек эшкуарлары, капитал ияләре булырга тиеш, дип раслый.

Әлеге әсәрен иҗат иткәндә, М. Акъегетзадәгә бары 20 яшь кенә була. Үзенең әсәре белән ул фикер-хисләрен, өмет-хы-

ялларын җиткерергә, шулар турында укучыны уйландырырга тели. Заманының проблемаларын ачык күзаллый һәм аларның чишелеш юлларын да тәкъдим итә. Билгеле, шул чор мөмкинлеге һәм фикери үсеше югарылыгыннан торып хәл итә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслекнең 121, 122 нче битләрендәге сорауларга нигезләнергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

«XIX гасыр мәгърифәтчеләре тудырган хатын-кыз образлары» яки «XIX гасыр әдәбиятында гаилә, һәм мәхәббәт темасы» дигән темага инша язарга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** XX гасыр башы татар әдәбиятына гомуми күзәтү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз эшчәнлегендә кеше, табигать һәм җәмгыять үсешенең төп закончалыклары, кешенең табигый һәм иҗтимагый мохит белән үзара бәйләнешләре турындагы фәнни күзаллауларның заманча системасына юнәлгән булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, уку мәсьәләсен (яки аның бер өлешен) чишү алгоритмын мөстәкыйль төзү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, аларны гомумиләштерү һәм чагыштыруның нигезен гамәлгә кертү, әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — XX гасыр башы татар әдәбияты үзенчәлекләре турында белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Ка-

зан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 123 — 130.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, күргәзмә китаплар (ХХ гасыр башы әдипләре һәм аларны өйрәнгән фәнни хезмәтләр).

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. ХХ гасыр башында иҗат иткән бертөркем язучыларның портретын куеп, аларны нинди уртаклык берләштерүе турында сорау бирергә мөмкин. Яки *сезгә Г. Тукай, Дәрдмәнд иҗатлары танышмы, аларның әсәрләрендә нинди проблемалар күтәрелә?* кебек сораулар укучыларны темага якынайта ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы сөйләшүгә нигезләнеп, укытучы ХХ гасыр әдәбиятының да халкыбыз тарихындагы азатлык көрәше, гадел җәмгыять төзү юлларын эзләү һәм шуларга бәйле кеше күңелендә барган үзгәрешләрне чагылдырган бай, катлаулы һәм гаять кызыклы әдәбият булуын искәртә.

ХХ гасыр башы сүз сәнгате турында сөйләшүне шул чор вакыйгалары, иҗтимагый — сәяси мәгълүмат бирү белән башлау кирәк. Төп вакыйгалар 1905 елгы буржуаз революция, 1917 елгы Февраль, Октябрь революцияләре, 1904—1905 елгы рус-япон сугышы, 1914—1918 еллардагы Гражданнар сугышы.

Әлеге вакыйгаларны телгә алу ук илдәге хәлләрнең гаять катлаулы булуын күрсәтә. Сугыш, революция кебек вакыйгаларның җимерү, афәт икәнлеген ачык аңласак та, без илдә капиталистик стройны җимереп, яңа социалистик җәмгыять төзү өчен барган көрәшнең, азатлык хәрәкәтенең уңай тәэ-

сирен, кешеләр күңелендә өмет, ышаныч, рухи күтәренкелек тудыруын да истә тотарга тиешбез. Илнең икътисадына җимергеч тәэсир ясаган, сәясәттә катлаулылык тудырган бу вакыйгалар кешенең рухи халәтендә яңа күтәрелешкә сәбәп була. Россия дәүләтендә яшәгән татар халкы да, азатлык хәрәкәтенә кушылып китеп, үзенең үсешендә яңа этапка аяк баса. Әлегә кадәр бары мөселман дөньясына йөз тотып, ислам дине кануннарына буйсынып, чит дин әһелләре, аларның гореф-гадәтләрен үзенә якын китерергә теләмәгән татар халкы патша самодержавиесе изүенә, дин кануннарын бозып, гади халыкны талап көн күрүче дин әһелләренә каршы көрәш байрагы астына берләшә. Алга таба укытучы дәреслекнең 28—29 нчы битләрендәге мәгълүматка нигезләнеп, җәмгыятьтә барган үзгәрешләрнең әдәби барышка тәэсирен аңлата. Күргәзмәгә куелган китапларны күрсәтеп, XX гасыр башы әдәбиятының күренекле вәкилләре белән таныштыра, укучыларның аларның кайсыларын белүләре, нинди әсәрләрен укулары турында әңгәмә корыла. Бу чор әдәбиятының бик бай булуы, алга таба татар әдәбияты үсешенә генә түгел, башка төрки халыклар әдәбиятына да зур йогынты ясавын истә тотып, әдәбиятыбызның «алтын дәвере» дип аталуы нигезләнә.

Бу чор әдәбиятының галимнәр тарафыннан тирәнтен өйрәнелгән булуын әйтеп, шул төркемгә караган китаплар белән таныштырыла.

Гомуми нәтиҗә ясаганда, түбәндәгеләргә игътибар итәргә кирәк:

1. Әдәбият халыкның иҗтимагый, сәяси тормышы, милли үзаңы, мәдәни үсеш югарылыгы белән турыдан-туры бәйләнешле. Шуңа әдәбиятта аерым халыкның милли үзенчәлекләре чагылыш таба. Бу — әдәбиятның **милли үзенчәлеге (характеры)** була. Ә язучының үз милләтенә булган хисләре, милләтпәрвәрлеге чагылу, милләтнең үткәне киләчәге турында фикер йөртүе әдәби әсәрдә милләт темасы, **милләт проблемасы** күтәрелү була. XX гасыр башы әдәбиятында бу мәсьәлә аерым урын алып тора.

2. Әдәбиятта заман идеологиясе чагылыш таба, әмма ул барыбер гомумкешелек кыйммәтләре, мәңгелек темаларны

читләтеп үтми, ә аларга үз заманы югарылыгыннан, аның таләпләреннән чыгып бәя бирә.

3. Һәр чор әдәбияты әлегә кадәр үзләштерелгәннән файдалана (форма, образлар системасы, тел-сурәт чаралары), димәк, традицияләр дәвам итә. Һәр чор әдәбияты (хәтта аерым бер язучы гына да) нинди дә булса яңалык өсти. Бу — яңачалык (новаторлык) дип атала.

4. XX гасыр башы әдәбияты электән килгән дини, рухи бергәлек белән береккән Шәрык әдәбиятына хас булган традицияләрне үзләштерә, саклый һәм дәвам итә. Әмма Россия дәүләтендә яшәү, җирле якынлык, аралашу, сәяси, икътисади яктан уртак тормыш алып бару, XX гасыр башындагы азатлык хәрәкәтенең үзара якынаюга этәргеч бирүе, халкыбызны рус һәм Европа мәдәнияте белән якыннан аралашуга этәрә. Шунлыктан татар әдәбияты үсешендә Шәрык һәм Гареб (рус, Европа) әдәбиятына хас үзенчәлекләр, кушылып (синтезлашып), әдәби яңарыш хасил итәләр.

XX гасыр башы шигърияттендәге үзгәрешләрне түбәндәге таблица аша чагыштыру юлы белән дә аңлатырга мөмкин.

| XX гасыр башына кадәр | XX гасыр башында |
|---|---|
| Идея-тематика | |
| Мәгърифәтчелек идеяләре өстенлек итә. Җәдитчелек-кадимчелек каршылыгы, хатын-кыз азатлыгы, әдәп-әхлак, гаилә, белем алу, милли алгарыш (тәрәккыят) мәсьәләләре шул югарылыкта хәл ителә. | Татар тормышын үзгәртеп кору идеясе өстенлек итә. Гади кеше бәхете мәсьәләсе алгы планга чыга. Ул иҗтимагый тирәлек, милләтнең гомуми хәленә бәйләп карала. Кеше, тәрбия җимеше булудан бигрәк, җәмгыятьтәге шартларга, социаль тигезсезлек, гаделсезлек мөнәсәбәтле тикшерелә. Тормышны үзгәртү өчен көрәш кирәклеге идеясе күтәрелә. Тематик яктан милләт язмышы, иҗтимагый гаделлек, гади кешенең тормышын сурәтләү, яшь буынны тәрбияләүдә яңалык, хатын-кызның җәмгыятьтәге урынын билгеләү. Яңарышны мәгърифәтчелек, фән-техника алгарышы, мәдәнилек, европалашу, иҗтимагый-икътисади үсеш белән бәйләп карау һ. б. |

| Жанрлар | |
|---|---|
| **Шигърияттә** төп жанрлар: мәдхия, мәрсия, газәл, дастан-кыйсса, шигъри хат, мөнәҗәт, табигать лирикасы. **Проза** әле формалашу кичерә. Жанр ягыннан авторлар үзләре хикәя, роман дип күрсәтәләр, әмма алар тулысынча бу жанр таләпләренә җавап биреп бетермәскә дә мөмкин. **Драматургиядә** беренче адымнар ясала. | **Шигърияттә** сәяси, фәлсәфи, сатирик, публицистик, гражданлык лирикасы үсә. Лиро-эпик жанрда романтик поэма, балладалар иҗат ителә. Аларда фольклордан килгән традицияләр үстерелә. **Проза** формалашып өлгерә. Хикәя, повесть, роман жанрлары калыплаша. Рус-Европа әдәбиятыннан килгән модернистик юнәлешле проза үсеш ала. Сатирик, фантастик проза туа. **Драматургиядә** иҗтимагый, гаилә конфликтына корылган драмалар, тарихи-инкыйлаби, фәлсәфи драмалар, комедияләр иҗат ителә. |
| Геройлар, образлар | |
| Шәрык әдәбиятына нигезләнгән образлар системасы өстенлек итә. Геройлар, мәгърифәтчелек идеяләреннән чыгып, кискен икегә бүленә: укымышлы һәм надан. Уңай геройның өстенлеге, укымышлы һәм җәдитче булуында. | Гади кеше (ялчы, көнлекче, вакытлы эшче, халык рухын саклаучы гади зат (сөннәтче бабай кебек), зыялылар, халыкка хезмәт итәргә алынган милләтпәрвәр затлар, эшче-большевиклар, тоткын, урталыкта калган геройлар, вак эш белән шөгыльләнүче сатирик образлар. |

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әдәбиятның иҗтимагый чор белән бәйләнешен ача алырлык сорауларга нигезләнелә. XX гасыр башы әдәбиятының әдәби үсешкә алып килгән яңалыгы төгәлләштерелә.

**VI. Өй эше бирү.**

Өйрәнелгән материалны ныгытырга. 129 нчы биттәге сорауларга җаваплар әзерләргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Әйдә халыкка хезмәткә (Габдулла Тукайның «Милләткә», «Милли моңнар» шигырьләре).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — социаль тәҗрибәне, үз яшенең төп эшчәнлегенә туры килә торган иҗтимагый рольләрне, тәртип, нормаларны һәм кагыйдәләрне төркемнәрдә һәм җәмгыятьтә өйрәнү һәм бәяләү; милләтенә, аның тарихына, мәдәниятенә карата ихтирам хисе булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, контекстны исәпкә алу һәм уку мәсьәләсен чишү барышында килеп чыгарга мөмкин кыенлыкларны алдан күрү, чишелешне үзгәрүчән шартларга яраклаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, әдәби һәм башка төр мәгълүматның ышанычлылыгын укытучы тәкъдим иткән яки мөстәкыйль рәвештә тәгъбир ителгән критерийлар буенча бәяләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Тукайның «Милләткә», «Милли моңнар» шигырьләренең эчтәлеген белү, идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 130—138.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Г. Тукай иҗаты сезгә танышмы?* дигән сорауга укучыларның фикерләре тыңланыла.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

XX гасыр башы шигърияте турында кыскача мәгълүмат биреп, Г. Тукай иҗатын өйрәнүгә күчелә. Бу этапта видеоролик материалын кулланырга була.

«Милләткә» әсәрен укырга керешкәнче, «милләт» төшенчәсе турында сөйләшү үткәреп алу уңай нәтиҗә бирәчәк. Күренекле татар галиме С. Максуди «Миллият тойгысының социологик әсаслары» исемле фәнни хезмәтендә «*кавем-милләт*» төшенчәсен кулланышка кертә һәм аны ыруг, кабиләләрнең бер дәүләт эчендә берләшүе нәтиҗәсендә туган этнос дип күрсәтә. Аныңча: «Кавем-милләт билгеле бер өлкәдә (территориядә) яшәгән, этнологик яктан тамырда оймак вә кабиләләрнең иң куәтле җитәкчелеге астында дәүләт булып берләшүе нәтиҗәсендә туган, бер телдә сөйләшүче, бер үк гореф-гадәтләр тотучы, бер үк дингә ышанучы, үзенә хас милли характеры булган, бер-беренә теләктәшлектә торучы вә охшаш кешеләрнең зур төркемедер»[1]. Бу бәяләмәдән күренгәнчә, милләт — кавеми-мәдәни бердәмлек. Милләтнең асылын тел берлеге, гореф-гадәтләре, инану-ышанулар уртаклыгы, тарихи вакыйга-хәлләрне бергәләп кичерүе тәшкил итә.

Галимнәр күрсәтүенчә, XIX гасыр ахырларына татар халкының милләт буларак формалашуы тәмамлана.

Һәр кеше — билгеле бер милләт вәкиле. Бу үзенчәлек аны башкалардан билгеле бер сыйфатлары белән аерып куя. Әйтик, авылда безне танымаган кеше: «Син кем кызы (улы)?» — дип сорый. Ераккарак китсәк, кайсы авылдан (районнан, өлкәдән) булуыбызны әйтеп танышабыз. Ә чит

---

[1] *Максуди С.* Миллият тойгысының социологик әсаслары. — Казан, 1999. — 137 б.

халыклар арасында без кайсы милләт вәкиле булуыбыз белән таныштырабыз. Татар милләте элек-электән әдәпле, пөхтә, эшчән, намуслы, сәүдәгәр һәм һөнәрле халык булуы белән аерылып торган.

Һәркем, үзенең гаиләсе, аның бердәмлеге, ныклыгы белән горурланган кебек үк, үз милләтенә хас матур сыйфатлары белән дә горурлана. Халкыңның үткәне белән таныш булу, милләтеңә хас үзенчәлекләрне белү, хөрмәт итү кебек сыйфатлар кешенең милли үзаң дәрәҗәсен билгели.

1905—1907 еллар революциясе татар халкының милли мәдәниятен һәм үзаңын үстерүгә, милли хокукый тигезлек, демократик ирек хәрәкәтенә көчле этәргеч бирә. Милли матбугат, милли театр барлыкка килү шуны күрсәтеп тора.

Г. Тукайның «Милләтә» («Милләткә») шигыре нәкъ менә татар халкының үзаңы күтәрелеш кичергән елларда языла. Шигырь 1906 елда 15 октябрендә «Әлгасрелҗәдид» журналында басыла. Шигырьнең оригиналын да, хәзерге телгә күчермәсен дә укыйбыз. Әсәрнең лирик герое кичергән хисләрне барлап чыгабыз:

— милләтенә мәхәббәт, олылау хисе (кичен, көндезен уйлый, күңеле «милләт» дигән сүзне сөя), милләте изге, хөрмәтле, аның турындагы хыялы да татлы, милләтен һәм милләткә булган сөю хисен ул һәрнәрсәдән өстен күрә («дөнья бирсәләр дә сатмам милләтемне, миллиятемне»), бу хисе гаять көчле, хәтта шашу дәрәҗәсендә.

— милләт шагыйре булу теләге («игелекле шагыйрең булырга ниятлимен», «мине милли ит, миңа шатлык бүләк ит», «мине шагыйрьлектә мәңге тугры ит, Тәңрем»). Бу хисе дә бик зур, бөтен теләк-омтылышын биләп тора;

— шагыйрьлек аша дан, үлемсезлек яулау теләге («тырышлыгым һәм эшләрем бушка китмәсен»), милләте аны дус күрсен («исемем үлмәсен», «онытылу үлемнән яманрак»), шагыйрьнең теләге, максаты: милләте аны хөрмәт белән, олылап искә алсын.

Лирик герой милләткә хезмәт итәргә алынган милләтпәрвәр шәхес буларак күз алдына баса.

Нәтиҗә ясыйбыз: шигырьдә милләт һәм шагыйрь арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның вазифалары ачыклана.

Шагыйрь — үз милләтенә гомерен багышлый, милләт гаме белән яшәп, аның саулыгын саклый. Димәк, ул шигырьләрендә үз милләтенең теләк-омтылышларын, рухи халәтен чагылдыра. Милләт аның хезмәтен бәяләп, исемен мәңгеләштерә.

Бу әсәрендә Тукай үзен милләт шагыйре дип игълан итә. «Нинди сыйфатлар шагыйрьне милләтнеке итә?» дигән сорауга җавап биреп, ул бу билгеләрне санап та чыга. Укучылар белән бергәләп табабыз.

1. Милләт гаме белән яшәү, милләтнең уңышлары өчен шатлану, милли үсештәге каршылыклар, тискәре яклар өчен борчылу, милли хәрәкәтнең әйдәүчесе булу.

2. Милләтне хөрмәт итү, һәрвакыт аңа тугры калу, бернинди байлык, кыйммәтләргә дә сатылмау.

Милли шагыйрь булу — аның өчен зур бәхет. Бөтен теләк-омтылышы милләтнең аны аңлавы, милли хисләр белән янып, милләт өчен тырышуын тануы белән бәйләнгән. Милләт тарафыннан читкә тибәрелү, онытылу үлемннән дә яман. Үлгәннән соң халык күңелендә яшәү — аның теләге, максаты һәм бәхете. Бу фикерләр әсәрдәге шигъри юлларны укып дәлилләнә.

Милли шагыйрь үз милләтенең рухын чагылдыра дидек. Милли кием, милли бизәк, милли аш, милли бию, милли көй һ. б. сүзтезмәләренең мәгънәсенә төшенеп карыйк. Милли сыйфатлар, димәк, аерым бер милләт өчен генә хас булган нәрсәләр. «*Милләт*» сүзенең мәгънәсеннән «*милли кием*», «*милли бизәк*», «*милли аш*» төшенчәләре барлыкка килә. Аерым халыкның яшәү шартлары, эш-гамәлләре, хуҗалык алып бару алымнары, шөгыле, әхлакый кануннары аның милли үзенчәлеген тудыра. Милли киемдә иң беренче табигый шартлар (җылы якта һәм салкын якта кырыс табигый шартларда яшәгән кешеләр бер үк төрле киенә алмый), дини карашлар (ислам дине җанлы нәрсә сурәтләрен тыя), безне әйләндереп алган табигый дөньяның роле зур. Милли бию (әйтик, чегән һәм татар халык биюләрендә хатын-кызларның хәрәкәтләрен чагыштырсак, татар халкыныкында әдәп саклау, дәртнең эчкә яшерелүе сизелеп тора). Милли көй халыкның рухи халәтен, күңеленә

тулган гамен, уйларын чагылдыра. Туган җирен, сөйгәнен калдырып, ерак җирләргә бәхет эзләп киткән авыл егетләре җырлап юана, сагышын баса. 25 елга солдат хезмәтенә алынганнар да шулай ук, тыныч тормыштагылар да туган җирнең матурлыгын, хезмәт дәртен җырлый яки иҗтимагый тормышның гаделсезлекләрен көйгә сала:

*Җирән кашка гына һай атның,*
*Бөдрә ялкайларын җил тарый.*
*Бәхеткәйләрең генә булмагач,*
*Байга эшләп кенә кем баеый.*

Димәк, һәр милләт үзенчәлекле бер этник төркем булып формалаша, аның һәр сыйфатында миллилек чагылыш таба.

«Миллилек» төшенчәсен ачыклагач, «Милли моңнар» әсәрен укыйбыз. Шигырь самодержавие тарафыннан азатлык хәрәкәтен туктату өчен катгый чаралар күрелгән, иҗат әһелләренең ирегe кысылган 1909 елда язылган. Шуңа күрә «Милләтә» әсәрендәге рухи күтәренкелек биредә юк. Ул әчке сызлану белән алмашынган. Димәк, әсәрләрнең икесе ике пафос белән иҗат ителгән. Бу иҗтимагый вакыйгаларга бәйле.

«Милли моңнар» әсәрендә лирик герой чын, безнеңчә, матур, зарлы, моңлы, милли көй башкаруын ишетә. Бу көй аңа әчкә яшерелгән рухи халәте аша татар халкының катлаулы язмышын, аянычлы тарихын ачып бирә. Лирик герой, дөнья гаменнән аерылып, җырның моңы эчендә яши башлый. Ул зур дәүләтчелеге, халыкара аренада үз урыны булган халыкның хәзерге хәлен күз алдыннан кичерә. Милли көйнең моңы аның күз алдында шул тарихи вакыйгаларны яңарта. Җырда милләтнең гаме, күңеленә тирән яшерелгән уйлары чагылыш таба. «Милли хисләр белән ялкынланып», «сызылып-сызылып» күңелдән чыккан бу аһәңнәр «татар күңеле ниләр сизгәнен» (киләчәк турындагы уйларын да) әйтеп бирә. Лирик герой җан яраларын актарып ташлаган, бөтен зиһенне биләп алган бу көйнең исемен белергә тели. Милләттәше аңа бу көйне «Әллүки» дип белдерә.

Лирик герой кичерешләре аша шагыйрь җыр, көй белән халыкның язмышы, үткәне арасындагы аерылгысыз

бердәмлекне күрсәтә. Ул халкының үткәнен һәм хәзергесен дәвамлы рәвештә күңеленнән үткәрә. Аның киләчәге өчен борчыла, милләт гамен үзенең шәхси кайгысы хәлендә кичереп сурәтли.

Димәк, шигырьдә лирик герой кичерешләре халык кичерешләре белән тәңгәл килә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

XX гасыр башы шигъриятенә йогынты ясаган иҗтимагый шартлар, анда чагылыш тапкан азатлык идеясе һәм милли мотивлар, Г. Тукай иҗатында милли мотивларның калку сурәтләнешен хәтердә калдыру максат итеп куела.

**VI. Өй эше бирү.**

Г. Тукайның «Милләткә» шигырен ятларга

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Гөрләгән сулар ни сөйли? (Дәрдмәнднең тормыш юлы һәм иҗаты. «Видагъ», «Гөрләгән сулар» шигырьләре).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзенең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау, иптәшләренең җавапларын бәяләү; әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, аралашуда үзара җылы мөнәсәбәтләрне саклау.

*Предмет нәтиҗәләр* — Дәрдмәнднең тормыш юлы һәм иҗаты. «Видагъ», «Гөрләгән сулар» шигырьләренең эчтәлеген белү; идея-эстетик үзенчәлекләренә төшенү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары

өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 139—144.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Дәрдмәнднең нинди әсәрен белүләрен, нинди уңайдан (символ темасы) өйрәнүләре хәтергә төшерелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрдмәнднең тормыш юлы, эшчәнлеге һәм иҗаты белән танышуны видеороликка нигезләнеп алып барырга була.

Укытучы Дәрдмәнд иҗаты турында өстәмә рәвештә таныштыра ала.

XX йөз башы татар шигъриятендә Дәрдмәнд — бер үк иҗтимагый-сәяси шартларда иҗат мәйданына аяк баскан чордашларыннан әсәрләренең идея-тематик эчтәлеге белән дә, тел-өслүбе ягыннан да аерылып торучы шагыйрь. Беренче рус инкыйлабы вакыйгаларының милләт язмышына йогынтысына ул үзенчә бәя бирә. Бу үзгәрешләрне С. Рәмиевчә таң вакытына тиңләми, Тукайча, кояш көнбатыштан чыкты дип, гайре табигыйлек күрми. Дәрдмәнд каләменә үз заманының вакыйгаларын киң тарихи яссылыкта ачу бурычын йөкли.

Аяк астыбыз кан, күз яше, кыерсытылганннар зары, билгесез корбаннар белән тулган. Дәүләтебезне саклап шәһит киткән бабаларыбыз кабере, аталар рухы алдында бурычыбыз да түләнмәгән, тагын бу кан кою кирәкме? дигән сорау куя.

Дәрдемәнд — фәлсәфи, романтик лирик. Аның иҗатында романтизмның ике канаты да — пессимизм да, оптимизм да

урын алган, күп кенә урыннарда бу ике хис бергә үрелеп китә.

Дәрдмәнд яшәеш принципларын, тормыш кануннарын билгели: ата-анага мәрхәмәт кыл, изгелек үзе балаларыңнан кайтыр («Нәсыйхәт»), югарыга таш атма, сине кирәксенмәгәннәр арасына үзеңне мәҗбүриләмә («Беренче апрельдә зыярәт портретын җибәргән дустыма»), тормыш каккан дулкында йомычка булма, дөньяны үз кулыңда тотарга тырыш.

Дәрдмәнд үзен татар халкының тулы хокуклы бер вәкиле итеп саный һәм моның белән горурлана:

*Татарлыктан татар һич гарь итәрме,*
*Кеше үз исемене инкяр итәрме.*
*Татарлыкта татар углы татармын,*
*Татар түгел димә — башыңны ватармын!*

Ил, халык язмышы аны уйландыра.Туган-үскән җир аңа ата-ана йортыннан да кадерлерәк («Ата-анам йорты өчен Булса мең җаным фида; Туган-үскән җирем өчен соң тамчы җаным фида»), милләте белән аны сөт һәм кан кардәшлеге берләштерә. «Гөрләгән сулар башында» шигырендә ул «Кораб» һәм «Бүзләрем мана алмадым» шигырьләрендәге күңел сызлануларына фәлсәфи югарылыктан торып нәтиҗә ясый.

«Гөрләгән сулар башында» шигыре укып анализлана.

Дөнья буйлап таралган милләтебезне, нинди ватанда яшәүенә карамастан, сөт һәм кан берлеге үзара якынайтып, берләштереп саклаячагына ышаныч белдерә. Ил, халык язмышындагы фаҗиганы, үзенең шуларга каршы тора алмаслык көчсез икәнлеген аңлап, күңел төшенкелегенә бирелгән вакытларда да, рухын күтәрерлек таяныч эзли:

Ни газизрәк — бу ватанмы?
Аһ, туган каүмем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
    Сөт калыр, ватан китәр!
    Сөт калыр, ватан китәр!

Ватан җирлегендә барган үзгәрешләрне ул тарихи чор таләбе буларак кабул итә.

Алга таба «Видагъ» шигыренә анализ ясала. ул «Гөрләгән сулар башында» шигырен тематик яктан дәвам итеп килә. Аларны туган җир, Ватанннның газизлеген аңлау берләштерә. Образлар системасындагы, хисләрдәге уртаклык та шуның белән бәйле.

«Видагъ» шигырендә ул туган җире, тормышының бәхетле мизгелләре белән бәхилләшә. Ни өчен бәхилләшә? дигән сорауга, Дәрдмәнднең биографиясенә нигезләнеп, укучылар җавап бирә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәрдмәнд иҗатына хас сыйфатларны барлау, иҗатының үз биографиясе белән тыгыз үрелгәнлеген, милли рухлы фәлсәфи шагыйрь булуын укучыларның аңлап калуларына ирешү кирәк.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәрдмәнднең лирик герое турында сөйләргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Үткән материалны кабатлау. Контроль эш. Нәтиҗәләр чыгару.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — татар әдәбияты, шулай ук рус әдәбияты әсәрләрен өйрәнү контекстында күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә Россия гражданлыгы тәңгәллеген аңлау; төрле уртак эшчәнлеккә әзер булу, үзара аңлашуга һәм үзара ярдәмләшүгә омтылу, шул исәптән әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да;

*Метапредмет нәтиҗәләр* — әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү, нәти-

җәләр чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү.

*Предмет нәтиҗәләр* — белемнәрне системалаштыру, гомумиләштерү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 9 нчы сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. Укучыларның әдәбият дәресләрендә нинди яңалыклар белүе, бу дәресләрнең аларда нинди фикер тудыруы турында сөйләшү үткәрелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әңгәмәдән чыгып, дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Кабатлау, белемнәрне системалаштыруны укытучы сыйныфның белем дәрәҗәсенә карап, үзе теләгән формада оештыра.

Мәсәлән, аны укылган әсәрләргә сәяхәт рәвешендә үткәрергә мөмкин.

Ул берничә этаптан торырга мөмкин. Шулай ук сыйныфның әзерлеген истә тотып эшләнә.

Түбәндә аның берничә этабын күрсәтеп үтәрбез.

Таблицаның зурлыгын укытучы көйли. Кайсы графаны буш калдыруны да үзе хәл итә.

| Әсәрнең язылу вакыты | әсәр исеме | авторы | иҗат юнәлеше |
|---|---|---|---|
| ? | «Хисаметдин менла» | ? | Мәгърифәтчелек реализмы |
| XX гасыр башы | «Милләткә» | ? | ? |

**Әсәрләрнең жанрын билгеләргә:**

«Сөннәтче бабай»

«Өч арышын җир»

.......................

**Өзек кайсы әсәрдән?**

*Бу мәктүпне язып, туташымыз, әкертен атлап, бакчага теге казык янына чыкты. Чөнки менланың мәктүбендә җавапны тап шул кичтә куярга кирәклеге әйтелгән иде.*

..............................

**Бу кайсы әсәрдән, кемнең портреты сурәтләнгән?**

*Йөзең алсу кызыл гөлтик (гөл кебек),*
*Яңагың кызыл алматик;*
*Кызыл алма кеби кызны*
*Насыйп итәр микән Алла?*
*Кашың кара тумышыңдан,*
*Битең һәм якты гөлбөстан,*
*Сәнең тик зифа җан дустан*
*Аермасын Кәрим Алла!..*

Сорау, биремнәрне укытучы үзе теләгән күләмдә алырга мөмкин.

**IV. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреснең бу этабында гомумиләштерүче сораулар белән эшләнә. Мәсәлән, түбәндәге сорауларны бирә алабыз.

Бу уку елында кайсы әсәрләрне яратып укыдыгыз?

Кайсы әсәр күңелегездә күбрәк сакланып калды?

Кайсы эпизодны сөйләп бирә аласыз?

Кайсы герой күзалдыгызда тора?

Кайсы әсәр авыр укылды?

Бу уку елындагы әдәбият дәресләреннән нинди тәэсирләр калды, нинди тәкъдимнәр кертә аласыз?

**V. Өй эше бирү.**

Җәй көненә биремнәр бирелә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Яхшы теләкләр белән хушлашабыз.**

---

## ЭЛЕКТРОН РЕСУРСЛАР ИСЕМЛЕГЕ

www.antat.ru/ru/iyli/publishing/book/uchebniki — Дәреслекләрнең электрон формалары.

www.antat.ru/ru/tatzet — Татар теле: зур электрон туплама.

https://magrifat.antat.ru — Укытучылар, әти-әниләр һәм балалар өчен мәгълүмати ресурс.

https://photo.miras.info/№ — «Татарское визуальное наследие» сайты

www.belem.ru — Татар мәгарифе порталы.

www.balarf.ru — Интерактив мультимедия китапханәсе.

http://tatarile.tatar — «Татар иле» укучылар өчен электрон энциклопедиясе.

www.ganiev.org — Русча-татарча тавышландырылган онлайн сүзлек.

www.tatarhistory.ru — Татарстан тарихы буенча электрон атлас.

www.tatarcartoon.ru — «Татармультфильм» берләшмәсе эшләгән анимацион фильмнар җыентыгы.

Учебное издание

**Абдуллина** Дилария Маратовна
**Мухарлямова** Гульназ Нурфатовна

РОДНАЯ (ТАТАРСКАЯ) ЛИТЕРАТУРА

**9 класс**

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
основного общего образования, работающих с обучающимися,
владеющими родным (татарким) языком

*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Абдуллина** Диләрия Марат кызы
**Мөхәрләмова** Гөлназ Нурфат кызы

ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ

**9 нчы сыйныф**

Методик әсбап
Төп гомуми белем бирү оешмаларында
(туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

Мөхәррире *А. А. Дәүләтова*
Рәссамы *Д. Л. Нәүрузова*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *Л. И. Матвеева*

Подписано в печать с оригинал-макета 21.08.2024
Формат 60×84 1/16.